ТАТАР КЕШЕСЕ

Җанисәп нәтиҗәләре уйланырга да, борчылырга да мәҗбүр итә

> 5

ТЫРЫШКАН ТАБАР

Белгечләр эш алыштырганчы кат-кат уйларга киңәш итә

> 6

РАИЛ САДРИЕВ:

«Аңламаган кешеләр өчен генә сәер мин»

> 18–19

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 8 (28975) | Җомга | 20 гыйнвар | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

«БЕЗГӘ КИЛЕП КҮРЕГЕЗ!»

ВИДЕОЯЗМАЛАР БӘЙГЕСЕ • ГРАН-ПРИ – 50 000 СУМ!

«Ватаным Татарстан» газетасы, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү комиссиясе белән берлектә, «Безгә килеп күрегез!» дигән зур бәйге игълан итә! Эшләр видеоязма форматында булырга тиеш. Җиңүче интернетта тавыш биру һәм жюри әгъзалары бәяләмәсе буенча ачыкланачак.

Бәйгенең шартлары 20 нче биттә >

Ишетми калмагыз

Роспотребнадзор вейпны (электрон сигарет) закон дәрәҗәсендә тыю тәкъдимен хуплаган. Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин Россиядә аны тулысынча тыю тәкъдиме белән чыккан. «РИА Новости» хәбәренә караганда, Володин кушуы буенча булдырылган эш төркеме якын араларда электрон сигаретны үсмерләргә сатуны тыю һәм аның әйләнешен җайга салу буенча тәкъдимнәр әзерләячәк.

Моңа кадәр никотинлы әлеге продукцияне җитештерүдә күп кенә кимчелекләр ачыкланган. Аның составында хушбуй, чистартучы, һавага хуш ис таратучы матдәләр, кычынуга, талпаннарга каршы препаратлар табылган. Белгечләр бу матдәләрнең сәламәтлеккә зур зыян китерүе хакында кисәтә.

Татарстанда коронавирус йоктыручылар саны янә арта. «Стопкоронавирус.рф» порталындагы мәгълүматларга караганда, узган тәүлектә инфекция ияртүнең тагын 69 очрагы теркәлгән. Алдагы көндәгегә караганда 4 очракка күбрәк бу.

20 кеше хастаханәгә салынган, 59 кеше сихәтләнгән.

Шул рәвешле, пандемия башланганнан бирле республикада чир йоктыруның 194418 очрагы расланган. Узган тәүлектә үлем-китем булмаган.

Россия буенча мәгълүматларга килсәк, соңгы тәүлектә 5914 чир очрагы ачыкланган. 40 сырхау вафат булган.

Республикада, узган елның 28 сентябреннән башлап, мобилизацияләнүчеләргә барлыгы 4363 мәсьәлә буенча бушлай юридик ярдәм күрсәтелгән. Юстиция министры Рөстәм Заһидуллин әйтүенчә, министрлык хезмәткәрләре берничә тапкыр мобиль төркемнәр составында мобилизацияләнгәннәрне җыю пунктларына чыккан һәм аларга теге яки бу мәсьәлә буенча консультация биргән. Хәрби хезмәткә чакырылучылар ял көннәрендә дә кабул ителгән.

Бу хакта ул министрлыкның еллык коллегия утырышында әйтте.

Министр әйтүенчә, нотариуслар хезмәтенә ихтыяҗ аеруча зур булган. Алар барлыгы 3878дән артык бушлай хезмәт күрсәткән. Мобилизацияләнүчеләр шулай ук бурыч түләүне туктатып тору, кредит каникулы бирү мәсьәләләре буенча да еш мөрәҗәгать иткән.

Татарстанда явым-төшемсез, уртача дәрәҗәдә суык һава урнашты. Синоптиклар мәгълүматына караганда, ял көннәрендә республиканың көнбатыш районнарында аз гына кар көтелә. Шимбә, якшәмбе – 21, 22 гыйнварда – һава температурасы көндез –5…–10, төнге сәгатьләрдә –9…–15 градус, урыны белән –19 градуска кадәр төшәчәк.

Гидрометеоүзәкнең башлангыч фаразларына караганда, киләсе атна башында (23–24 гыйнвар) һава торышы әллә ни үзгәрмәячәк. Явым-төшем көтелми. Көндез термометрның терекөмеш баганасы –6…–11, төнлә –14…–19 градус чикләрендә тирбәләчәк.

Районнарда ни хәлләр?

Саба

Саба районыннан мобилизацияләнгән егетләргә якташлары «УАЗ» («Буханка» һәм «Фермер»), «Нива» автомобильләре илтеп бирде. Мобилизацияләнүчеләр янына чираттагы сәфәр февраль башларында планлаштырыла.
(«Саба таңнары»)

Актаныш

Узган ел районда көнкүрештә һәм исерек хәлдә кылынган җинаятьләр арткан. «Бу саннар җинаятьләрне күбрәк ачыклау сәбәпле арткан, әмма безгә хокук бозуларны булдырмау өчен, аерым категориядәге гражданнар белән эшне онытырга ярамый», – ди район эчке эшләр бүлеге җитәкчесе Рәдиф Баһавиев. Районда 2022 елда җәмәгать урыннарында кылынган җинаятьләр саны кимегән. Рәдиф Баһавиев район хакимияте ярдәме белән бүлекнең кизү тору частена видеокүзәтү үзәге куелуын әйтте. Актаныш авылын хәзер 114 камера төшереп тора.
(«Актаныш таңнары»)

Чүпрәле

Районның ЗАГС бүлеге 2022 елда иң популяр һәм сирәк балалар исемнәрен атады. 2022 ел нәтиҗәләре буенча, ЗАГС бүлегендә 75 бала теркәлгән. Шулай итеп, 36 малай, 39 кыз туган. Кызларга иң еш кушылган исемнәр – Амелия, Полина, Мирослава, София, Ясминә. Шулай ук Амилә, Зарина, Марина, Рәсилә, Эвелина кебек сирәк исемнәр дә сайлаганнар. Малайлар исемнәре арасында иң популяр исемнәр Кирилл, Ильяс, Марк, Матвей, Самат, Самир булган. Ә сирәк исемнәргә Артемий, Мәлик, Райхан, Русалин, Эмин, Эрик, Юлиан кергән.
(«Туган як»)

Зәй

Бигеш авылында яшәүче әниле-кызлы Мәгъсүмә апа белән Кифая Кәлимуллиналар ике сыер, бозау-таналары өстенә ике ишәк тә асрыйлар. Алар ишәкләренә яратып, малайлар, дип дәшәләр. «Кызымның күптәннән ишәк алдырасы килгән иде, хәзер ялга кайткач, оныклар да алар янынннан китмиләр. Ишәкләргә атланып йөриләр, аларны урамда да йөртәләр. Ишәкне асрау җиңел. Алар нәрсә бирсәң, шуны ашый, ризыкны талымламыйлар. Ипине бик яраталар, салам, печәнне дә теләп ашыйлар. Бик акыллы хайваннар. Баллы яраталар, ә минә суны бик эчмиләр», – ди Кифая апа.
(«Зәй офыклары»)

Әгерҗе

Районда өлкән яшьтәге пар никахларын теркәгән. Лев Романовка – 86, тормыш иптәше Лидия Игнатьевнага – 77 яшь. ЗАГС белгечләре әйтүенчә, яратырга беркайчан да соң түгел.
(«Әгерҗе хәбәрләре»)

АШХАБАДТА ОЧРАШУ

Рөстәм Миңнеханов Төрекмәнстанда сәфәрдә. Татарстан Президенты ил делегациясе составында Россия – Төрекмәнстан бизнес форумында катнашты.

Халыкара чарага кадәр Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Ашхабадта Төрекмәнстан парламентының Югары палатасы – Милли Генгешнең Халык Маслахаты рәисе Гурбангулы Бердымөхәммәтов белән очрашты. Гурбангулы Бердымөхәммәтов билгеләп үткәнчә, Россия – Төркмәнстан мөнәсәбәтләре кысасында, Ашхабад Татарстан белән хезмәттәшлек итүгә зур әһәмият бирә. Казанда Төрекмәнстан генераль консуллыгы ачылу да ике арадагы элемтәләрне ныгыткан. «Татарстан компанияләренең Төрекмәнстанда эшчәнлек алып барулары да сөендерә», – дигән Гурбангулы Бердымөхәммәтов. Ул Рөстәм Миңнехановка «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме җитәкчесе буларак Төрекмәнстанда уздырылучы чараларда катнашуы өчен рәхмәт әйтте.

Бүген Татарстан һәм Төрекмәнстан нефть чыгару, нефть эшкәртү, машина төзелеше кебек тармакларда хезмәттәшлек итә. Сәүдә-икътисадый мөнәсәбәтләрдән тыш, ике якны гуманитар өлкә дә бәйли. Рөстәм Миңнеханов әле яңа гына Казанда



tatarstan.ru

ислам илләре һәм Татарстанның һәвәскәрләр командалары арасында узган «Kazan Hockey Cup 2023» халыкара турниры турында искә алды. Ә Төрекмәнстан Ислам илләре хоккеен үстерү ассоциациясен оештыручыларның берсе булып тора. Татарстан вузларында Төрекмәнстан студентлары саны да елдан-ел арта. Бүген республикада әлеге илдән килгән 6 меңнән артык егеткыз белем ала. Рөстәм Миңнеханов Гурбангулы Бердымөхәммәтовка Татарстанга игътибарлы булганы өчен рәхмәт әйтте.

ДАРУ БЕЛӘН ГЕНӘ БУЛМЫЙ

Медицина тармагына игътибар, табибларга ярдәм булачак. Әмма кеше үзе дә сәламәтлеген кайгыртырга тиеш. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы коллегиясендә шул хакта сөйләштеләр. Президент Рөстәм Миңнеханов узган ел республикада үлем-китем күрсәткече кимүне төп нәтиҗә дип атады.

Арттырасы түгел

2022 елда республикада үлүчеләр саны, 25,8 процентка кимеп, бер мең кешегә 11,5 очракны тәшкил иткән. Иң түбән күрсәткечләр Питрәч районында, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт һәм Казан шәһәрләрендә теркәлгән. Кайбыч, Яңа Чишмә, Түбән Ослан, Чүпрәле һәм Апас районнарында исә үлүчеләр саны, киресенчә, арткан. «Узган ел эшкә яраклы яшьтәге 9 мең кешенең гомере өзелгән. Бу – барлык үлүчеләрнең 22 проценты дигән сүз. Сез уйлап карагыз!» – диде сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков.

Министрлыкның бүлек җитәкчесе Елена Игнашева әйтүенчә, соңгы 20 елда балалар арасында үлем-китем очраклары 3,5 тапкыр кимегән. Актаныш, Буа, Мөслим, Спас, Тәтеш, Чирмешән районнарында, әйтик, 17 яшькә кадәрге бер генә бала үлеме дә теркәлмәгән. Зәй, Аксубай, Әтнә районнарында исә бу яктан саннар югары.

Узган ел Татарстанда халыкның уртача гомер озынлыгы 3,3 елга арткан. Министр моны тармакта ирешелгән иң зур уңышларның берсе дип саный. Республикада яшәүчеләрнең уртача гомер озынлыгы – 74 яшь. Ил күләмендә ул 72не тәшкил итә. 2030 елга 78кә җиткерү күздә тотыла.

Алдан кисәтү мөһим

Сәламәтлек саклау тармагы эшчәнлегендә төп максат үлем-китем саннарын киметеп, гомер озынлыгын арттыруга барып тоташа. Моның өчен нәрсәләр эшләнә?

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, узган ел республиканың сәламәтлек саклау тармагын үстерүгә барлыгы 104 миллиард сумнан артык акча бүлеп бирелгән. Шуларның 10 миллиард сумнан артыгы медицина объектлары төзү, төзекләндерү, медицина җиһазлары алу өчен тотылган. Рөстәм Миңнеханов узган ел республикада үлем-китем саннары кимүне дә зур нәтиҗә дип атады.

– Профилактик эшне көчәйтергә, сәламәт яшәү рәвешен популярлаштырырга кирәк. Халыкка диспансеризация һәм профилактик чаралар уздыру җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Ерак авылларда яшәүчеләргә аеруча зур игътибар бирергә кирәк, – диде Президент. Диспансеризация узганнарның 10,3 процентында авыру ачыкланган.

Рөстәм Миңнеханов Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының, югары технологияләр кулланып, трансплантология өлкәсендә зур уңышларга ирешүен дә билгеләп үтте.

– Ясалган операцияләр саны, 2021 ел белән чагыштырганда 1,8 тапкыр артты. Бу – 147 кешенең гомере саклап калынган дигән сүз. Бавыр күчереп утырту буенча – 55, бөергә – 84, йөрәккә шундый 8 операция ясалган. Без Республика клиник хастаханәсе базасында трансплантация үзәге төзелешенә дә ярдәм итәбез, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Дөрес, Президент тармакта элек-электән күзәтелгән кайбер кимчелекләрнең әле дә сакланып килүен искәртте. Табибка язылганда килеп туган кыенлыклар, халыкның медицина ярдәме мөмкинлекләреннән тулысынча хәбәрдар булмавы, белгеч белән авыру арасындагы мөнәсәбәтләр... Яшерен-батырын түгел, көндәлек тормышта бу проблемалар белән очрашырга туры килә әле.

Чистайда да булачак

Узган ел Татарстанда 7 йөрәк-кан тамырлары үзәге ачылган. Яңа үзәкләр Арча, Әлмәт, Буа, Түбән Камада, Казанның 18 нче һәм 12 нче хастаханәләрендә, Сугыш ветераннары госпиталендә эшләп килә. Быел Чистай район хастаханәсе базасында да шундый үзәк барлыкка килачәк.

Республикада икенче ел рәттән беренчел звено тармагын яңарту эше дә алып барыла. Бу эш «Сәламәтлек» илкүләм проекты кысасында башкарыла. Аның нигезендә узган ел республикада 32 объект төзелгән. Әле Яңа ел алдыннан гына Казан янындагы Көек авылында яңа амбулатория эшли башлады. Марат Садыйков, быел Осиново бистәсендә – яңа хастаханә, Дәрвишләр бистәсендә балалар хастаханәсе ачылачак, дип вәгъдә бирде.

Районнарда яшәүчеләрне дә онытмыйлар. Быел Татарстанда районнарга йөрүче бишенче күчмә хастаханә пәйда булачак. Узган ел «тәгәрмәчле хастаханә»дә табиблар республиканың 23 районындагы 118 торак пунктта яшәүче 28 мең кешене тикшергән. Шуларның 3 меңгә якынында беренче тапкыр чир барлыгы ачыкланган.

Рәхмәт

Марат Садыйков белдерүенчә, соңгы өч ел дәвамында республиканың медицина тармагы катлаулы шартларда эшли. Алдагы елларда яңа зәхмәт – коронавирус котырса, узган ел дуңгыз гриппы да өстәлде.

– Илдәге геосәяси вакыйгалар да сәламәтлек саклау тармагына йогынты ясады. Чикләүләр аркасында медицина җиһазлары, дарулар кайтаруда кыенлыклар, махсус хәрби операция башлану, безгә күчеп килүчеләргә һәм мобилизацияләнүчеләргә дәвалау, тернәкләндерү дисеңме... Республика клиник хастаханәсе белән Казанның 7 нче шәһәр хастаханәсендә эшләүче хезмәткәрләребез яңа республикаларда яшәүчеләргә дә ярдәмгә ашыкты. Хәзерге вакытта да Луганск Халык Республикасында Татарстанның педиатрлар бригадасы эшли. Алар 4 меңнән артык балага ярдәм итәргә өлгерде инде, – диде Марат Садыйков.

Батыр табибларга коллегиядә катнашкан Татарстан Президенты да рәхмәт белдерде. «Катлаулы хезмәтләре, үз-үзен аямаулары, сабырлыклары өчен медицина хезмәткәрләренә зур рәхмәт әйтәсем килә», – диде Рөстәм Миңнеханов. Ә җыелыш алдыннан Президент медицина тармагында хезмәт куючы 96 гаиләгә социаль ипотека программасы буенча төзелгән йорттан яңа фатир ачкычлары тапшырды.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЯЗГЫ СЕССИЯ БАШЛАНА

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының кырыгынчы утырышы 26 гыйнварда узачак. Парламент Президиумы утырышында шундый карар кабул ителде. Аны Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин үткәрде.

Депутатлар язгы сессиянең беренче утырышында 15 мәсьәләне, шул исәптән 4 республика законы проектын һәм 9 федераль закон проектын карап тикшерергә ниятли.

Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина билгеләп үткәнчә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге, халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында республика законнарына, шулай ук Татарстанның Җир, Гаилә кодексларына үзгәрешләр кертү турында закон проектлары беренче укылышта карап тикшерүгә әзерләнгән. Аерым алганда, Гаилә кодексының 45 нче статьясына һәм мәгариф турында республика законының 14 нче статьясына үзгәрешләр уллыкка (кызлыкка) алынган балаларга абый-апалары (бертуган яки бертуган булмаган) укый торган мәгариф оешмасына укырга керү буенча өстенлекле хокук бирүне күздә тота.

Дәүләт Советында Хөкүмәтнең узган елдагы эшчәнлеге буенча хисапны карап тикшерү эше башланган инде. Аерым алганда, Президиум утырышында республика башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында комитетлар һәм депутатлар берләшмәләреннән алынган сораулар исемлеге расланып, республика Президентына юлланды. Бу сорауларга җаваплар, еллык хисап белән бергә, Дәүләт Советына алыначак.

Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, Хөкүмәтнең узган елдагы эше турында депутатлардан 36 сорау кергән. Аларның күпчелеге республика икътисады һәм бюджетына бәйле. Парламент башлыгы әйтүенчә, сәяси һәм икътисадый вазгыятьнең читтән тыш катлаулы булуына бәйле бу.

– Былел, икътисадый өлкә белән беррәттән, мәгариф һәм мәдәният өлкәсе буенча да сораулар байтак, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Комитетлар һәм фракцияләр тәкъдиме буенча, сораулар исемлегенә Татарстанда яшүсмерләрне ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү пункты кертелгән. Өч өлкә – социаль сәясәт, сәламәтлек саклау, җәмәгать иминлеге өлкәләре буенча сайлаучыларның проблемаларын чагылдырган сораулар тупланган.

Биредә сүз социаль газлаштыру программасын тормышка ашыру, торак-коммуналь хуҗалык тарифлары үсүне тоткарлауга юнәлдерелгән чаралар, күпбалалы гаиләләргә бүлеп бирелгән җир кишәрлекләрен үзләштерүгә ярдәм итү, зур шәһәрләрнең яңа микрорайоннарында мәгариф оешмаларын, хастаханәләр һәм сырхауханәләр төзү, мәктәп медицинасын үстерү өчен шартлар тудыру, педагогларга ярдәм итү чаралары турында бара.

Президиум утырышында шулай ук Дәүләт Советының 2023 елга эшен оештыру чараларының үрнәк планы расланды.

ӘГЕРҖЕДӘ – ЯҢА ҖИТӘКЧЕ

Әгерҗене Ленар Нургаянов җитәкләячәк. Район советының чираттагы утырышында аны башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын башкаручы итеп сайладылар. Моңа кадәр район башлыгы булып эшләгән Азат Вәлиев исә үз теләге белән эшеннән китте. Утырышта Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты.

Азат Вәлиев, узган елгы эшләре турында хисап тотканда, районда тулай территориаль продуктының 8,4 млрд сумга җиткәнен әйтте. Бер ел эчендә райондагы эре һәм урта предприятиеләрдәге уртача хезмәт хакы, 11 процентка артып, 39891 сумга җиткән. Районда «Әгерҗе» логистик сәнәгать паркы төзелә. Аңа 5,4 миллиард сум күләмендә инвестиция салырга ниятлиләр, 300ләп яңа эш урыны пәйда булыр дип көтелә. Районда туризм тармагын да үстермәкчеләр. Красный Бор авылында туристик кластер төзергә җыеналар.

Фәрит Мөхәммәтшин узган ел башкарылган эшләр өчен район җитәкчелегенә рәхмәт белдерде. Шулай да Әгерҗе социаль-икътисадый үсеш рейтингында 41 нче урында гына тора. Дөрес, аннан алдагы елда район өч баскычка астарак булган. Дәүләт Советы Рәисе булган мөмкинлекләрдән нәтиҗәле файдаланырга кушты.

– Уртада гына таптанып тормагыз. Сезнең алдынгылар арасында булган заманнар да бар иде бит. Димәк, мөмкинлекләр бар, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Әгерҗедә тырыш халык яши. Шушы өстенлектән файдаланып, республика җитәкчелеге ярдәме һәм Әгерҗе халкының тырышлыгы белән вазгыятьне уңай якка үзгәртеп булыр дип өметләнәм.

Утырышта Әгерҗе район башлыгы Азат Вәлиевнең отставкасын кабул иттеләр. Аның белән беррәттән Башкарма комитет җитәкчесе Рөстәм Шәрипов та вазыйфасыннан китәргә теләк белдерде.

– Мин һәрчак район халкы мәнфәгатьләрен кайгыртып эшләдем. Күп кенә проблемалы мәсьәләләрне хәл итеп булды, эшлиселәре дә житәрлек. Без агым уңаена гына бармадык, яңа проектлар уйлап таптык, Әгерҗе районының абруен күтәрү өчен тырыштык, – диде Азат Вәлиев.

Район советының чираттагы утырышында башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын башкаручы итеп Ленар Нургаяновны сайладылар. Ул – тумышы белән Әгерҗенең Тирсә авылыннан. Ун елдан артык районның авыл хуҗалыгы сәнәгате оешмаларында эшләгән. Аннары хезмәт юлын Алабуга районында дәвам иттергән. Авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы, башкарма комитет җитәкчесе булып эшләгән. «Сез Әгерҗе районы һәм аның халкы алдына куелган катлаулы бурычларны уңышлы гына башкарып чыгарсыз дип өметләнәм», – диде Фәрит Мөхәммәтшин яңа җитәкчегә.

Әгерҗега Ленар Нургаянов җитәкчелек итәчәк.

Президент ашыгырга киңәш итте

Былтыр Татарстанда янгыннар һәм утта һәлак булган кешеләр саны сизелерлек кимегән. Шөкер, алдагы ел белән чагыштырганда, су корбаннары саны да азрак теркәлгән. Тик республика коткаручыларына тынычланырга иртәрәк. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының еллык коллегиясендә якын арада ук яшеренү урыннарын рәткә китереп бетерергә куштылар.

Башкалада Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсе һәм Татарстан Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ел йомгакларына багышланган уртак утырышы узды. Чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

– Узган ел безнең өчен шактый катлаулы булды, – диде идарә башлыгы Рафис Хәбибуллин. – Пандемия, махсус хәрби операция башлану, Россиягә каршы кертелгән санкцияләр шартларында без республика халкының иминлеген тәэмин итүгә бәйле бурычларны ышанычлы рәвештә үтәдек.

Тик алга таба эшне тагын да көчәйтергә туры киләчәк. Рөстәм Миңнеханов республиканың котелмәгән хәлләргә әзер булып торырга тиешлеге басым ясап әйтте. Татарстанда якын арада ук сыену урыннарын яңадан барлап, аларны әзер хәлгә китереп куячаклар. Татарстанда һава һөҗүменнән качу урыннарының өчтән бер өлеше, ул-бу була калса, халыкны яшерергә әзер түгел. Булганнарын рәткә китереп, яңаларын төзү бурычын да куйдылар утырышта. Кем әйтмешли, сакланганны саклармын, дигән Аллаһ.

– Илнең башка төбәкләре бу мәсьәлә белән күзгә-күз очрашты инде. Яшеренү урыннары, халыкка хәбәр җиткерү системасы тәртиптә булырга тиеш. Бүгенге шартларда бу аеруча мөһим. Безнең алда зур бурычлар тора. Барысы да әзер булырга тиеш, ашыгырга кирәк, – диде Президент.

Ул республика халыкка хәбәр итү системасының торышы камил түгеллекне дә билгеләп үтте. Рөстәм Миңнеханов тиешле чаралар күрергә өндәде.

Былтыргы эшкә йомгак та ясадылар. Татарстанда янгыннар саны кимегән. Алдагы ел белән чагыштырганда, былтыр мондый очраклар 20 процентка азрак теркәлгән.

– Вазгыять республиканың барлык районнарында да диярлек уңай якка үзгәрде. Бердәнбер искәрмә – Алексеевск районы. Янгыннар саны белән беррәттән, утта һәлак булучылар саны да кимеде. Алдагы ел белән чагыштырганда, утта үлүчеләр саны өчтән бер өлешкә азрак. Аерма бик зур. Утта 117 кеше һәлак булган. Аларның күбесе – исерекләр, – диде идарә башлыгы.

Сүз уңаеннан, Татарстанда йортларда янгын чыгуны кисәтүче җайланмалар кую эше дәвам итә. Былтыр республикада 19 мең йортта шундый 52 меңнән артык җиһаз урнаштырганнар. Узган ел шулар ярдәмендә 91 кешенең гомерен саклап калганнар.

Рөстәм Миңнеханов белдергәнчә, махсус хәрби операция башлану бөтен тармакларга да тәэсир итте. Бу юнәлештә республика коткаручылары башкарган эшне югары бәяләде ул. «Халыкның куркынычсызлыгын тәэмин итү ул – өстенлекле бурычларның берсе. Сыйфатлы хезмәтегез өчен зур рәхмәт», – диде Президент. Ул Татарстан алдында барлыкка килгән проблемаларны уңышлы рәвештә хәл итә алачагыбызга ышаныч та белдерде.

– Безнең халык башкаларның хәленә битараф булмавы белән аерылып тора. Без Донецк һәм Луганск халык республикаларыннан, Запорожье һәм Херсон өлкәләреннән 2 меңнән артык кешене кабул иттек, шул исәптән 500гә якын бала килде. Бүген вакытлыча урнаштыру пунктларында 665 кеше бар. Калганнары республика шәһәр һәм районнарындагы туганнарында яши. Уртак тырышлык белән без Донецк һәм Луганск халык республикаларына 1328 тонна гуманитар йөк җыйдык һәм илтеп тапшырдык, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Әйтеп кенә бактым

Иртәнге фәлсәфә

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Туган көнем алдыннан дусларга-танышларга телефоннан шалтыраттым. «Иртәгә мине котларга онытмагыз!» – дидем. Берәүләр: «Ярый, искә төшерүеңә рәхмәт!» – диде, икенчеләре сәер генә көлеп җибәрде. Бәлки, яше барган саен ычкына бу абзый, дип уйлаганнардыр. Бер танышым: «Ну, хохмач та инде үзең», – дип куйды. Тел белгечләре «хохма» – борынгы яһүд сүзе, безнеңчә «зирәклек» дигәнне аңлата, диләр. Мин моңа ышанам, чөнки, кайчак әйтәсе сүземне маңгайга бәреп әйтү килешмәс дип уйлап, үземә дә башны җүләргә салырга туры килә. «Җүләргә салу» сүзеңне уены-чыны белән әйтү була инде.

Мин үз-үземне белгәннән бирле шаяртырга яратам. Әни миңа: «Син кечкенәдән бик тыныч бала идең, туганда да еламадың», – ди торган иде. Әгәр еламаган икән, димәк, көлеп туганмындыр, һич югы, авыз чите белән елмаеп куйганмындыр. Һәрхәлдә, шулай дип уйлыйсы килә.

17 гыйнвардагы шаяртуларым, ягъни хохмаларым 18 гыйнварда үз җимешләрен бирде: әче таңнан кичкә хәтле котлаулар кабул итеп утырдым. Мине кешегә санаучыларның һәркайсына зур рәхмәт. Әгәр бер көн алдан: «Мине котларга онытмагыз!» – дип кисәтмәгән булсам, бу хәтле дәрәҗәләргә ирешә алмас идем. Баксаң, мин бик талантлы шәхес икән, гаилә җанлы, үрнәк ир икән… Кем икәнлегемне белми үлеп китә язганмын, әстәгъфирулла, тәүбә, тәүбә…

Миңа шактый югары дәрәҗәдәге бер җитәкченең: «Бу заманда һәр нәрсәне сорап алырга кирәк», – дип әйткәне бар. Заманга нәрсә булды икән соң ул, әй? Ни өчен бер-беребезнең кадерен белми башладык? Бер-беребезнең уңышларына сөенәсе урынга ни өчен көнләшәбез? Кара көнләшү белән бит әле ул! Мин бу сорауларга тәгаен генә җавап бирә алмыйм, башым җитми. Әллә «Аз рәхәткә, күп михнәткә түзә адәм баласы…» – дип җырлауларыбыз дөрес микән?

Бүген «Бергә булыйк, бердәм булыйк!» – дип, кем иренми – шул әйтә. Әмма бердәмлек барыбер җитми, берәр авырлык килсә сизсәк, үз кабыгыбызга кереп бикләнергә дә күп сорамыйбыз, афәт җиле безгә генә килеп кагылмасын. Кая инде ул «Ялгыз кайгы – кайгымыни, илгә кайгы килмәсен…» – дип җырлаулар!

Без – сугыштан соң туган балалар, образлы итеп әйткәндә, туплар гөрелтесе тынып кына килә иде әле. Өстәлендә бер телем артык икмәк булган гаилә иң бәхетле гаилә санала иде. Кеше шул икмәкне бүлешергә әзер тора, күршесен чәйгә чакыра иде. Самавыр янында елмаеп-көлеп сөйләшеп утыралар иде, вәт «хохмач»лар. Халык бик зирәк булган, түзем булган, бөтен авырлыкларны бергә җиңеп килгән. Бу, бәлки, җәмгыятьнең төрле социаль катлаулардан тормавына да бәйле булгандыр. Бай кеше ярлы-ябагай белән кочаклашып-җырлашып йөрми бит инде! «Бергә булу, бердәм булу» өчен бөтен кешенең йә ярлы, йә бай гына булуы кирәк микәнни? Чистый аптыраш, диярсең.

Кичә генә интернетта яңалыклар карап утырдым. Украинада махсус хәрби операция башланыр алдыннан, кайбер олигархлар һәм түрәләр «тиенләп» җыйган миллиардларын кеше күзеннән читкә алып куйганнар, йә балалары исеменә күчергәннәр, ди. Дәрестерме бу, шайтан белсен: байларны чит илләргә сәфәр чыгулардан вакытлыча тыю турында да сүз бара. Кемдә нәрсә кайгысы инде.

Бу язманы төгәлли алмыйм әле, туган көн белән котлап һаман шалтыраталар. Дусларга алдан әйтеп куеп дөрес эшләдем, көндәлек мәшәкатьләр белән монннан 74 ел элек дөньяга аваз салуым турында онытып та җибәргән булырлар иде.

Теге җитәкче сүзләре тагын искә төште әле. Чыннан да, бөтен нәрсәне сорап алырга кирәк микәнни бу дөньяда? Шулайдыр, бүген Җир шарында 8 миллиард кеше яши, кемгә ни кирәген кем исәпләп барсын, кем белеп бетерсен ди? Еламаган балага имчәк бирмиләр инде ул. Миңа исә бары да җитә, иң әһәмиятлесе, мин исән, туганнарым, дусларым исән-сау. Инде, картлар әйтмешли, Ходай илгә-җиргә генә тынычлык бирсен иде. Бердәмлеккә килгәндә, бер җыр тел очымны гел кытыклап тора бит. Шуны җырлыйм да эшкә чыгып китәм:

Алай да бергә-бергә,
Болай да бергә-бергә.
Безнең бергә булуыбыз
Калсын бөтен гомергә…
Әйт шуны!

САНКЦИЯЛӘР: КУРКЫНЫЧМЫ-ЮКМЫ?

Владимир Путин сишәмбе көнне икътисад мәсьәләләре буенча видеоконференция режимында киңәшмә үткәрде. Кремль лидерының вазыйфасы шундый: ул төшенке рухтагы бер генә җөмлә дә әйтергә тиеш түгел. Үткәннәргә нәтиҗә уңай, киләчәккә фаразлар оптимистик булырга тиеш. Күз алдыгызга китерегез: ил җитәкчесе чыгып: «Эшләр харап, без бетәбез», – дисә, халык нишләячәк?

Президент Путинның үткән елга биргән бәясе мондый: «Күп кенә белгечләр 20 процентка түбәнәю көтсә дә, эчке тулай продуктның кимүе 2,5 процент кына булды». Лидер икенче кварталдагы кискен түбәнәюдән соң, өченче һәм дүртенче кварталларда үсеш теркәлүен дә билгеләп үтә. Инфляция динамикасы да яхшы, ди. Үткән ел нәтиҗәләре буенча акча очсызлану 11,9 процент булса, 2023тә беренче кварталда – инфляция 5 процент, икенче кварталда 4 процент тирәсе булыр дигән фараз да әйтелде. Болар барысы да яхшы, әлбәттә, һәм иң мөһиме: ялган түгел. Кайбер тармакларда инфляция урынына дефляция дә күзәтелә хәтта.

Бу юлларның авторы һәрвакытта да дефляциягә – бәяләр түбәнәюгә дан җырлады. Әмма процент капиталына корылган базар икътисадында дефляция – начар күрсәткеч, ул халыкның сатып алу мөмкинлеге төкәнүен һәм икътисад тәгәрмәченең кирегә әйләнә башлавын хәбәр итә. Халык керемнәрен кредит түләүгә тота икән, яңа продуктлар сатып ала алмый, инфляция күрсәткече шул сәбәпле төшә, шуның аркасында дефляция килеп чыга. Дөрес итеп файдаланганда, дефляцияне икътисадның үсеш моторына әйләндерергә була, әмма икътисадның хәзерге моделе моңа юл куймый. Ул бәяләрнең акрын гына күтәрелеп торуын сорый һәм эчке тулай продуктның да 4–5 процентлык үсешен таләп итә. 2,5 процентлык түбәнәю күрер күзгә кечкенә булып күренсә дә, бүгенге финанс системасы өчен фаҗига ул.

Моны сатарга дип йорт төзүче оста позициясенә басып аңлатабыз әйдә. Ул банктан ун йорт төзергә дип кредит алган иде, әмма төзелеш материалларына бәя күтәрелү сәбәпле, җиде яки сигез генә йорт төзеде. Кредитны шартлы рәвештә мең берәмлек дип алабыз. Процентлары белән кайтарып бирү өчен, якынча мең ике йөз – мең биш йөз тирәсе берәмлек акча эшләү таләп ителә. Банк проценты күпме булуга карап инде. Төзүче шуңа өмет иткән иде дә, йортлар бәясе 20–50 процентка артачак дип бизнес-план төзеде. Әмма ул теләгәнчә килеп чыкмады, мең берәмлеккә сигез генә өй җиткереп булды, җитмәсә бәяләр дә 20 процентка түгел, биш процентка гына үсте. Яисә төште дә хәтта. Бәя төшүен күргән халыкның йорт алу теләге кимеде, тагын да очсызлануын көтә башлады. Төзелгән сигез йортның алтысын гына сатып булды. Төзүче кредитларын ничек итеп түли?

Бәя төшү – кулланучылар өчен тантана һәм бәйрәм ул, ә җитештерүче өчен – фаҗига. Бәянең көтелгәнчә үсмәве дә – хәсрәт хәтта. Бу схемада банкка нечкәлекләр дә күп әле. Аларның барысын да исәпли башласаң, җитештерү түбәнәю шартларында инфляция кимүнең икътисадый коллапсның алды булуын сиземли алабыз. Ул коллапстан котылу өчен, Путин дөрес максат куя: «…нужно стимулировать занятость и рост заработных плат – реальных заработных плат», – ди. Хезмәт хакларын күтәрү, бигрәк тә фәкыйрьләргә түләүне арттыру – бу вазгыятьтә бердәнбер котылу тәгәрмәче, әмма ул да озак сроклы перспективада балансларның югалуына китерә һәм катастрофаны якынайта. Бу хакта безнең сүз озайтырга мәйданыбыз юк, булса, исәпләп күрсәтә алыр идек.

Әйдәгез, хәзер Путин йомгагына үзебезнең нәтиҗәне өстибез. Ни өчен 2022 ел 20 процентлы түнтәрелеш китереп чыгармады? Моның объектив сәбәпләре бар. Беренчедән, углеводородларга бәяләр котчыккыч югары торды һәм безнең нефтьне, газны, хәтта ташкүмерне дә Көнбатыш күпләп сатып алырга мәҗбүр булды. Ташкүмергә эмбарго августтан гына керде, газга әлегә бернинди эмбарго да юк, әмма көзге якта аның сатылуы шулай ук кискен чикләнде. Нефть эмбаргосы һәм «түшәм» бәяләр декабрьдә генә гамәлгә куелды, нефть продуктларына тыю 5 февральдән керә. Бүген ул тыюга кадәр Көнбатыш безнең дизель ягулыгын гадәттәгедән күбрәк тә сатып ала хәтта. Углеводородлар сәүдәсендә артка китеш әле башланып кына килә һәм ул 2023 елның икенче-өченче кварталларында чынлап кайтаваз бирәчәк. Сату кимер, бәя төшәр дигән фараз урынлы.

Икенчедән, Көнбатыш санкцияләренә «дус илләр» дип аталган Азия гигантлары һәм Төркия кушылмады. Арзанрак булса да безнекен сатып алдылар, үз товарлары белән безнең базарны тутырырга тырыштылар. Евросоюз бу көннәрдә санкцияләрнең унынчы пакетын әзерли һәм ул пакетта төп стратегия – Вашингтон һәм Брюссель керткән санкцияләргә буйсынмаган илләргә икенчел санкцияләр кертү. Бу юнәлештә алар уңышка ирешсә, без егылабыз, оттырсалар, алар егылачак. Үзләре егылганда, алар безне дә өстери инде, барыбыз бергә түнәчәкбез. Базар шартларында санкцияләр кертү – бик начар нәрсә ул, кертүченең үзе өчен дә начар.

Өченчедән, Россия түнтәрелешен хәрби-сәнәгать комплексы булдырмый калды. Путинга сүз бирик: «За последний год он набрал серьезные обороты и продолжает наращивать мощности. Предприятия работают в несколько смен, некоторые – практически круглосуточно». Хәрби-сәнәгать комплексының нәрсә икәнен СССРда яшәп караганнар белә. Ул чакта барлык икътисад диярлек хәрби өлкәгә хезмәт итә иде. Хәтта бәрәңге киптерү заводлары да армиягә эшләде. Бу халыкны эш белән тәэмин итә, бик күп ресурсларны үзенә тарта. Әйтик, корыч кою заводлары эшсез тормый. Беренче карашка алар икътисадның гражданлык тармагы кебек, әмма хәзер барыбер хәрби сәнәгатька хезмәт күрсәтә. Эчке тулай продукт арта, әмма, гафу итегез, киләчәктә икътисад өчен бу зур проблемага әверелачәк.

Базарда килеп туган дисбалансны халык кулланучы товарларын импортлап кына көйләп булыр иде, әмма моның өчен бездә җитәрлек акча булырмы һәм безгә ул товарларны сатарлармы? Бу 2023 елның төп проблемасына әверелергә мөмкин һәм ул проблема борынлап ята инде. Тагын «Российская газета»ны ачабыз. Анда «ОСАГО упало до нуля: вместо ремонта выплачивают деньги, которых не хватает» дигән язма урын алган. Хәзер авариягә эләксәң (Аллаһ сакласын инде), машинаңны ремонтламыйлар, кулыңа иминиятләштерү акчасын гына тоттыралар, әмма ул акча кече телгә дә йокмый, чөнки запчастьлар юк, булса да котчыккыч кыйммәт. Без акрынлап икътисадның совет моделенә күчәбез: кибеттә арзан, әмма юк, базарда бар, ләкин кыйммәт. Санкцияләрнең беренче гөрелтесе дип санйык моны. Алда тоташ күк күкрәүләр башлануы ихтимал. Кулга мул социаль түләүләр тоттырырлар, әмма алар бернигә дә ярамас. Статистикада барысы да яхшы күренер: эчке тулай продуктның артуын күрербез (саннар ялган булмас, чын булыр), әмма базар хәлләре сөендермәс. Без совет чорында шулай яшәдек: корыч кою буенча Американы уздык, мамык җыю, ит җитештерү күрсәткечләре дә әйбәт иде. Ашлыкны күп җыйдык, онны чит илдән сатып алдык. Совет кытлыгының берничә сәбәбе бар иде. Берсе – бар ил белән хәрби-сәнәгать комплексына эшләү, икенчесе – Африка һәм Азия илләренә мул ярдәм күрсәтү, өченчесе – базарларда товарларның итәк астына яшерелүе. Андый вазгыятьтә акча-ришвәт мөнәсәбәтләре артқы планга күчә, кул кулны юа дигән принципка нигезләнгән, без онытып бетергән йонлач кул, блат төшенчәләре алга чыга.

Әлегә Россия сумының элекке совет республикаларының кубесендә дәрәҗәсе бар. Ноябрь аенда безнең банкларда бер долларны 65 сумга алыштырып булганда, Кыргызстанда 61 Россия сумына алыштырып була иде. Мондый иркенлек тукталачак. Соңгы көннәрдә генә бер яңалык ишеттем: Казахстан сумны тәңкәгә турыдан-туры алыштырудан баш тарта. Сум өчен мәйдан тарау бездәге кытлыкны үстерәчәк. Илдән капитал качу темплары 2022 елдагыча булса бигрәк тә. Санкцияләр шулай акрын эшлиләр инде алар. Бармакны ярыкка тыккач: «Кысмады!» – дип кычкырырга ашыкмыйк шуңа күрә. Чөйне кагып чыгаралар икән, котылгысыз рәвештә кысачак. Каршы яктан чөй кагып кына бармакны саклап калып була. Кремльдә, бәлки, бардыр андый чөй, әлегә безгә күрсәтүче юк.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

САНАЛ(МА)ДЫК

ҖАНИСӘП НӘРСӘ БЕЛӘН ИСТӘ КАЛАЧАК?

Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы? Бөек шагыйребез Габдулла Тукай мәкаләсендәге әлеге юллар бу көннәрдә гел телгә килә. Дөресрәге, декабрь азагында кабат кисәк кенә үзгәреп куйган кәефебезне чагылдыра кебек. Билгеле булганча, узган елның 30 декабрь кичендә илдә җанисәп нәтиҗәләрен игълан иттеләр. Аларның нинди тәэсир уятканын аңлау өчен, бер санны атау да җитә. Илдә татарлар 600 меңгә (!) диярлек кимегән. Бу коточкыч күренешкә нәрсә сәбәпче? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауга җавап эзләде.

Җанисәп башыннан ук сул аягыннан торган көйсез кешене хәтерләтте. Бердән, бар халык, дөньялардан ваз кичеп, коронавирустан куркып яшәгән тынгысыз пандемия чорында уздырылды ул. Аны уздыру вакытын да ике тапкыр күчерделәр. Шул рәвешле, 2020 елда узасы җанисәп 2021 елда үтте. Ахыры хәерле булсын дигән теләкләр дә кабул булып бетмәде бугай. Чүп өстенә чүмәлә рәвешендә уздырылган җанисәпнең нәтиҗәләре дә иң уңышсыз вакытта – халык бар кайгысын читкә куеп торып, Яңа ел каршыларга әзерләнеп йөргән көннәрдә игълан ителде.

Тарих фәннәре кандидаты Илнар Гарифуллин моны махсус эшләнгән адым дип саный.

– Яңа ел елларында халык җанисәп турында искә алмас, ишетсә дә, игътибар бирмәс, аннары инде дөньяда барган хәлләр аркасында, анда гаме калмас, дип өметләнгәннәрдер. Һәм моңа ирештеләр дә диярлек. Күп кенә милләт вәкилләре җанисәп нәтиҗәләрен күрмичә дә калды. Халык санын алу – сәяси операция. Ул илнең зур икәнен, бай икәнен күрсәтергә ярдәм итә. Безгә дә үзебезне күрсәтү өчен мөмкинлек бирә ул. Халыкны күбрәк итеп күрсәткән саен, ил дөньяда көчлерәк булып күренә. Кызганыч, бу җанисәптә без әлеге PR-акцияне уңышлы башкарып чыга алмадык, – ди белгеч.

Телсез арасыннан эзлисе

Җанисәп нәтиҗәләреннән күренгәнчә, соңгы унбер елда Россиядә яшәүчеләр саны, 4,3 миллион кешегә артып, 147,2 миллионга җиткән. Шул ук вакыт эчендә Татарстанда яшәүчеләр саны да, 218321 кешегә артып, бүген 4 миллион 4809ны тәшкил итә. Республикада яшәүче халыкларның 52 проценты – татарлар. Ике җанисәп арасында татарлар 78604 кешегә арткан. Аның каравы ил күләмендә милләттәшләребез коточкыч дәрәҗәдә – 597 меңгә кимегән.

Без элемтәгә кергән белгечләр барысы да беравыздан диярлек җитешмәгән татарларны үз милләтен күрсәтүдән баш тарткан кешеләр арасыннан эзләргә кирәк дип саный. Алары исә тагын да гаҗәпкә калдырды. Ник дигәндә, быелгы җанисәп барышында Россиядә 16,5 миллион кеше милләтен күрсәтүдән бөтенләй баш тарткан. Чагыштыру өчен: 2010 елда уздырылган җанисәп барышында андыйлар саны 5 миллион 311 мең кеше булган.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров фикеренчә, бу саннар үзләре үк татарларның кимүе турында мәгълүматның дөреслеккә туры килмәвен исбатлый.

– Татарлар 600 меңгә кимемәде, алар саналмады гына. Бөтендөнья татар конгрессының экспертлар комиссиясе бәяләмәсе нигезендә шуны әйтә алам: бүген Россиядә яшәүче татарлар 5 миллион 500 меңнән дә ким түгел. Безнең саннарның Росстат мәгълүматлары белән тәңгәл килмәвенең сәбәпләренә килгәндә, барыбыз да беләбез: халык санын исәпкә алу вакыты пандемия чорына туры килде. Быелгы җанисәптә 16,5 миллион кеше үз милләтен бөтенләй күрсәтмәгән. Җитешмәгән татарлар санын да шуннан эзләгез. Пандемия аркасында сан алучылар безнең барлык милләттәшебезгә дә барып җитмәгән. 1990 нчы еллар азагындагы демографик упкынның да йогынтысы юк түгел. Җанисәптә Дәүләт хезмәтләре порталы аша да катнашып була иде бит, диярсез. Әмма авыл җирләрендә, бигрәк тә читтәге татарлар яшәгән авылларда интернет белән тәэмин ителеш ташка үлчим. Булган очракта да өлкәннәрнең аннан файдалана белүе икеле, – ди Данис Шакиров.

Таңсылу Галимова

Исәпкә генә алынмаган

Җитешмәгән татарларны милләтен күрсәтмәүчеләр арасыннан эзләргә кирәклегенә тагын бер күренеш ишарә ясый. Татарлар иң күп кимегән төбәкләрдә үз милләтен күрсәтмәүчеләр саны да иң зурлардан. Җанисәп нәтиҗәләреннән аңлашылганча, соңгы ун ел эчендә Мәскәү шәһәрендә, Ульяновск һәм Чиләбе өлкәләрендә яшәүче татарлар саны аеруча нык кимегән. Мәскәү шәһәрен генә алыйк. Ун ел эчендә анда яшәүче татарлар саны 64670 кешегә кимегән. Шул ук вакытта биредә 3 миллион кеше үз милләтен бөтенләй күрсәтмәгән. Ун ел эчендә 60 меңнән артык татарын югалткан Чиләбе өлкәсендә яшәүчеләрнең 15 проценты да – милләтен күрсәтмәүчеләр рәтендә.

Тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков эре шәһәрләрдә халыкның күпләп кимүенә аптырарлык түгел дип саный.

– Халыкның күпчелеге эре шәһәрләрдә юкка чыкты. Биредә халыкның 30 процент чамасы халык санын алуга эләкми. Елның-елында шул хәл. 16,5 миллион кешенең милләте дә, туган теле дә булмау берничек дөреслеккә туры килә алмый. Бу кешеләргә халык санын исәпкә алучылар гомумән килмәгән. Андыйлар турында мәгълүматны исә полиция кебек органнардан алып тутыралар. Гамәлдәге закон нигезендә исә бу өлкәдә кешенең милләтен дә, телен дә теркәргә ярамый. Бүген татарлар күбрәк зур шәһәрләрдә яши. Җанисәпкә бәйле кимчелекләр дә нигездә зур шәһәрләргә бәйле. Халкыбыз беркая да югалмаган, аларны исәпкә генә алмаганнар, – ди галим.

Чәчелмәсәң җайлырак

Җанисәп нәтиҗәләре буенча сан ягыннан шактый калышкан кебек тоелсак та, татарлар Россиядә иң киң таралган милләтләр арасында, руслардан соң икенче урынны саклап кала алган. Белгечләр менә монысын иң зур нәтиҗә дип саный. Бу күрсәткеч буенча, чуаш белән башкортларны артта калдырып, алтынчыдан өченче урынга чеченнар чыккан. Ун ел эчендә аларның саны 243494 кешегә арткан.

Яшерен-батырын түгел, милли үзаң турында сөйләгәндә, еш кына чеченнар үрнәк итеп китерелә. Әмма белгечләр чеченнарның сан ягыннан алдыруына бер яктан гына карамаска киңәш итә.

Данис Шакиров фикеренчә, халкың читкә сибелмичә, бер тирәдә яшәгәндә, сан ягыннан алдырып яшәү җайлырак.

> Татарларның 30 проценты гына Татарстанда яши. Калган 70 проценты дөнья буйлап сибелгән. Башка халыкларда читкә сибелү дәрәҗәсе ул кадәр түгел. Аларның сан ягыннан артулары да, нигездә, шуңа бәйле.

Тарихчы Дамир Исхаков та, Кавказдагы мәгълүматлар ышанычлы түгел, дигән фикердә. «Алар барысы да – дотация ала торган республикалар. Халык күбрәк булса, дотация дә күбрәк килә. Шуңа күрә андагы саннарның дөреслеккә туры килеп бетмәве ихтимал», – ди галим.

Телең бел

Быелгы җанисәп милли үзаң турында да тагын бер кат уйланырга этәрә. Ул бездә ни дәрәҗәдә көчле дә, киләчәгебез нинди? Белгечләр бу уңайдан төшенкелеккә бирелү яклы түгел. Әмма үз киләчәгеңнең үз кулыңда икәнлеген дә истән чыгарырга ярамый.

Татарлар иң күп яшәгән 10 ТӨБӘК

Татарстан Республикасы	2091175
Башкортстан Республикасы	974533
Чиләбе өлкәсе	120242
Оренбург өлкәсе	116605
Ульян өлкәсе	111365
Төмән өлкәсе (Ханты-Манси һәм Ямал-Ненец автономияле округларын кертмичә)	96592
Самара өлкәсе	94452
Свердловск өлкәсе	93516
Пермь крае	92472
Мәскәү өлкәсе	84373

Журналист, җәмәгать эшлеклесе Римзил Вәлиев, милләтне, иң беренче чиратта, туган тел билгели, дигән фикердә.

– Татар икәнсең, син үз милләтең белән горурланырга, балаларың белән татар телендә сөйләшергә, аларны татар мәдәниятенә җәлеп итәргә, татар тарихын аңлатырга тиеш. Син татар дип язылган, әмма үз милләтең белән берничек тә кызыксынмыйсың икән, ике татар өйдә үзара башка телдә сөйләшә, баласы шуны тыңлап үсә икән, киләсе җанисәптә милләт тагын да кимеячәк дигән сүз. Туган тел ул милләтне билгеләми, диләр. Әмма шунысы хак: ул кешенең үзаңы ни дәрәҗәдә булуын, милләтенә тугрымы-юкмы икәнлеген төгәл күрсәтә, – ди ул.

Быелгы җанисәп исә Татарстанда 3 миллион 261155 кешенең татар телен белүен күрсәткән. Көндәлек тормышта исә аны 2,9 миллион тирәсе кеше генә куллана икән. Җанисәп барышында үзен «татар» дип атаучыларның 86 проценты татар телен туган теле дип атаган. Соңгы унбер елда андыйлар саны 6 процентка арткан. «Татар телен беләм», – дип җавап бирүчеләр сафы исә 11 процентка кимегән.

Тарих фәннәре кандидаты Илнар Гарифуллин фикеренчә, бүген милли горурлык төшенчәсен арттыру да мөһим.

– Яшьләрдә милли үзаң юк, дип әйтергә яратсалар да, булган хәлендә бар ул. Алар белән дөрес итеп эшләү генә җитеп бетми. Чөнки күпчелек татар оешмаларының, милли сәясәт өчен җаваплы кешеләрнең идеологик яктан тәҗрибәләре юк. Алар элеккечә эшлиләр. Яшьләр белән эшләү өчен исә концерт үткәрү генә җитми. Идеология, пропаганда ягыннан карарга, шул ук интернет аша эш алып барырга кирәк, – ди белгеч. – Яшьләрдә миллилекне тарихи хәтер аша гына үстерергә мөмкин. Һәйкәлләр куюмы, мәгълүмат чараларында ниндидер проблема күтәрүме… Яшьләрнең күбесе хәзер онлайн режимда яши. Ә анда бу эш алып барылмый. Татарлыкны үстерү өчен, бездә милли горурлыкны үстерергә кирәк. Татарларны күбрәк сувенир халык итеп күрсәтергә телиләр. Алар чәй эчә дә өчпочмак, чәкчәк ашый кебек фикер яши. Ә безгә көчле, үз милләтен яраткан, татарлыгыннан баш тартмаган, үзен яклый белә торган халык образын тудырырга кирәк.

Татарстан Дәүләт Советы депутаты Рамил Төхфәтуллин фикеренчә, киләсе җанисәптә тагын бер кат авыз пешмәсен өчен, безгә татар халкын барлый торган бәйсез, мөстәкыйль чараларны кулланырга кирәк.

– Моның өчен безнең, шул ук милли-мәдәни мохтариятнең дә, Татар конгрессының да мөмкинлекләре җитәрлек. Шуңа күрә безгә күпмедер дәрәҗәдә җанисәп вакытындагы эш форматын да үзгәртергә кирәк. Безнең даими эшли торган үзебезнең белгечләр үзәге дә юк бит. Без инде кайчаннан бирле үзебезнең татар мохитен булдыру турында сөйләшеп киләбез. Без үзебез мохит тудырмасак, читтәге татарлар каян илһамлансын соң? – ди депутат.

ЭШКӘ БИРСӘҢ ЧЫН КҮҢЕЛ...

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Работа.ру» порталы оештырган сораштыру нәтиҗәләренә караганда, быелтыр Россиядә яшәүчеләрнең 71 проценты эшен алмаштырырга теләгән. Моның өч төп сәбәбен дә атаганнар. Беренчесе – әлбәттә, хезмәт хакы, икенчесе – коллектив һәм җитәкчедән канәгать булмау, өченчесе – эшнең күплеге.

Хезмәт базары ризасызлык белдерүчеләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерерлекме? Кесәгә дә, күңелгә дә ятышлы эш табу мөмкинме? Белгечләр эш алыштырганчы кат-кат уйларга киңәш итә.

«Сезгә акча гына кирәкмени?»

Аида Зиннурова – белгечлеге буенча икътисадчы. Шәхси фирмада директор ярдәмчесе һәм менеджер булып эшли. Транспорт арендасы, логистика мәсьәләләре белән шөгыльләнәләр, кәгазь эше – аның җилкәсендә. Күңел тынычлыгы югалган көннәр күп, ди.

– Башка эшкә урнашу турында уйлар еш килә. Хезмәт хакыннан зарланмыйм, әмма эштән соң шәхси тормышка вакыт калмый да диярлек. Хәтта отпуск вакытында да берничә көнгә эшкә чыгарга туры килде быел. Җитәкчем – хатын-кыз. Аның белән уртак тел табу авыррак. Үзенеке дөрес дип саный. Кайчагында төнгә калып та эшлибез, квартал саен хисап әзерлибез бит. Өстәмә акча сораган очраклар да булды. Җитәкчемнең: «Ә сез эш урынында бары тик акча өчен генәме?» – дигәне истә. Ә тагын нәрсә өчен тәүлекнең 12 сәгатьтән артык вакытын бирергә уздырам икән соң мин? Әле 25 яшь тулмаган, әмма сәламәтлегем начар. Нерв күзәнәкләрен кем кайтарыр икән соң? – ди Аида. – Бездә еллар да юк, башка җирләрдәге кебек бәйрәмнәр үткәрү дә каралмаган. Әйтик, Яңа ел корпоративы, туган көннәр һәм башкасы. Ә бит эшләгәндә хезмәт урыныңдагы мохит тә бик мөһим.

Җәйгә таба эшеннән китәргә ниятләп тора Аида. Яңа урын эзләгәндә, хезмәт хакын да, җитәкчелекнең мөнәсәбәтен дә исәпкә алачакмын, ди. Эшли торган урынның яшәгән җиренә якын булуы да шарт.

Шәһәр төзекләндерү юнәлешендә бригада тотучы Инсаф та инде берничә ел шул теләк белән яши.

– Бездә «яхшы түгел инде» дигән кагыйдә бик яхшы эшли. Аеруча татарларда. Үзеңә кыен булса булсын, әмма башкаларны кыен хәлгә куясы килми бит. Миндә дә нәкъ шул, ахрысы, – дип аңлата ул моны. – «Гаиләне алып барасы бар, ипотека түлим, азрак акчаны арттырып булмасмы?» – дигәч, җитәкчем хезмәт хакын арттырган иде. Шул рәвешле тагын иске урында калдым. «Минем урынга тиз генә кеше таба алмаслар, аларга да кыен булыр бит», – дип уйландым. Ул чакта ук башка вакансияләр барлаган идем. Хәтта берничә урында сөйләштем дә. Офиста эшли торган, «ак яка»лар эше. Әмма яңа эшкә урнашу да җиңел түгел. «Комфорт зонасы»ннан чыгасы да килми икән. Бу эштә инде хезмәткәрләргә дә күнегелгән, көн дә нәрсә эшләячәгеңне ачык беләсең. Әмма үсеш кенә юк.

Гомуми вазгыять

Россиядә 561,1 мең кеше эшсез санала. Хезмәт базарындагы хәл тотрыклы. Узган елның ноябрь аенда эш бирүчеләр һәм белгечләр, РБК холдингы мәйданчыгында бергә җыелып, кадрлар мәсьәләсе турында фикер алышкан иде. Алар 2023 елда хезмәт базарына нәрсә тәэсир итәчәген фаразлады.

> Беренче чиратта, әлбәттә, төп бурыч – өлешчә мобилизация буенча чакырылган хезмәткәрләргә алмаш табу һәм IT белгечләргә кытлыкны каплау. Күпчелек компанияләргә инде 2022 елның сентябреннән ир-ат хезмәткәрләр җитми башлады. Нәтиҗәдә компанияләрнең 15 проценты – хатын-кызларны, 8 проценты – өлкәнрәк яшьтәге белгечләрне, 7 проценты вакытлыча һәм читтән торып эшләүчеләрне эшкә ала башлаган.

Россиянең Икътисадый үсеш министрлыгында 2022 елда эшсезлек дәрәҗәсе – 4,8 процент, ә 2023 елда 5,2 процент булыр дип фаразлаганнар иде. Ләкин былтыр җәй бу күрсәткеч 3,9 процентка кадәр төште. Хәзер ул, Россия Президенты Владимир Путин сүзләренчә, 3,7 процентны тәшкил итә.

Хезмәт базарында кем хуҗа?

Халыкара хезмәт оешмасы да шушы көннәрдә эшсезлеккә бәйле хисап белән уртаклашты. Эшләмәүче бер ир-атка ике эшсез хатын-кыз туры килә икән. Дөнья күләм караганда, узган ел хатын-кызларны эш белән тәэмин итү дәрәҗәсе 47,4 процентны тәшкил иткән. Ир-атларныкы – 72,3 процент.

Россиядәге вазгыятькә исә «SuperJob» хезмәте ачыклык кертте. Демографик хәлнең һәм махсус хәрби операциянең вазгыятьне үзгәртүен алар да инкарь итми. Эшче куллар җитмәү кайбер һөнәрләрдә хатын-кызлар өлешен арттырып җибәргән. Әйтик, 9 ай эчендә сату буенча менеджер, курьер, комплектлаучы, программа тәэминатын сынаучы вакансияләре буенча эш эзләүче хатын-кызлар 5–6 процентка арткан.

Моннан тыш, эш эзләүче ир-атларның яше арту күзәтелә. Мисал өчен, система администраторлары, механик, аппаратура һәм контроль-үлчәү җиһазлары инженерлары – 3, сакчы, фрезеровщик, энергетика өлкәсендә эшләүчеләр, балта осталары 2 яшькә «картайган».

Татарстандагы вазгыятькә килгәндә, узган ел нәтиҗәләре буенча мәшгульлек күрсәткече 62,8 процентны тәшкил иткән. Идел буе федераль округы буенча да (59,5 процент), ил буенча да уртача күрсәткечтән (60 процент) күбрәк бу.

Сәнәгать зоналарында да кадрлар кытлыгы сизелә. Бу аеруча Кама аръягында күзәтелә икән. Казанда да 16 меңнән артык вакансия бар. Әлеге дә баягы эшче куллар кирәк.

Кече һәм урта бизнес өчен кадрлар табу белән шөгыльләнүче белгеч исә яңа эш урыны эзләүчеләргә менә нәрсәне истә тотарга киңәш итте:

– Быел эш сорап килүчеләрдән һөнәри осталык, тәҗрибә, стресска каршы торучанлык кына түгел, ә үзгәрә торган шартларга тиз арада яраклаша алу да сораладачак. Берьюлы берничә эшне башкара алырдай кадрларны яраталар. Катлаулы бурычларны чишүдә иҗади якын килү, яңача алымнар куллана белү дә хуплана. Аннан, мәгълүматны анализлый белү дә мөһим. Бер өлкәдә генә түгел, башка тармаклар буенча да белем һәм күнекмәләре булса, бик яхшы.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Киңәш

Бер тапкыр кискәнче, җиде кат уйлыйсы. Психологлар да шулай дип кисәтә. Яңа эш урыны эзләргәме, эштән китәргәме, дип баш ваткан арада кайбер кагыйдәләрне истә тотарга өндиләр.

✓Көтелмәгән хәлләр килеп чыкса, эш бирүче яңа килгән кешене эштән иң алдан азат итәчәк. Яңа хезмәткәрләрне кыскарту, сынау чорында эштән китү турында гариза яздырту, эштән җибәрү күпкә җиңелрәк.

✓Теге яисә бу компания яңа төрле вазыйфага кеше эзли икән, димәк, бу компания хезмәт базарында үзен тотрыклы һәм иркен тота дигән сүз. Андыйлар, күпчелек очракта, бөтен икътисадый хәтәрне исәплиләр.

✓Ниндидер сәбәпләр аркасында, хәзерге эш урыныгыз үзегезне канәгатьләндерми икән, иртәме-соңмы бу эш нәтиҗәсенә тәэсир итәчәк.

✓Яңа вакансиягә килергә ризалашканчы, барлык кызыксындырган сорауларны биреп калыгыз (бик гади тоелганнарын да!). Ниндидер кырын эшләр, шикле схемаларга риза булмавыгызны әйтеп куегыз. Эш бирүче турында да күбрәк белешергә кирәк.

Наил ХАФИЗОВ, «Авито.Работа» хезмәтенең Татарстандагы төбәк вәкиле:

– Гомумән алганда, 2023 елда безне производстводагы белгечләргә ихтыяҗ артуы, төрле социаль төркемнәрнең хезмәт эшчәнлегенә активрак җәлеп ителүе һәм Шәрык телләрен белгән белгечләргә ихтыяҗ көтә. 2022 ел нәтиҗәләре буенча, «Авито.Работа» аналитиклары да ил күләмендә вакансияләр саны артуын күзәтә (+69 процент). Тәкъдимнәр буенча лидер тармаклар – сату (13 процент), җитештерү (12 процент) һәм төзелеш (9 процент). Казанда да шулай ук дияргә була: 52 процентка вакансияләр арту күзәтелә. Алдынгы рәтләргә сату (14 процент), җитештерү (12 процент) һәм төзелеш (8 процент) тармаклары чыкты. Бу саннар хезмәт базарының актив булуын сөйли. Эш бирүчеләр күп санлы кандидатлар арасыннан, ә эш эзләүчеләргә вакансияләр арасыннан сайлау мөмкинлеге булды.

Быел хезмәт базарына гомумикътисадый факторлар йогынты ясаячак:

– Росстат мәгълүматларына карасак, демографик вазгыятьнең начараюы 2030 елга 20–39 яшьтәге эшләүчеләрнең санын киметәчәк;

– 2024–2025 елларда эчке тулай продуктның үсеше күзәтеләчәк;

– эшсезлек буенча минималь күрсәткеч сакланачак.

Җитештерү тармагында кадрларга ихтыяҗ импортка алмаш, модернизация, җитештерүчәнлекне арттыру, логистиканың үзгәрүе белән аңлатыла. Төзүчеләр яллауга бәйле активлык юл төзелешләре гөрләве һәм милек базарындагы вазгыятькә бәйле.

Шәрык телләрен белгән белгечләргә дә ихтыяҗ үсәчәк. Бу исә Россия базарына Төркия, Кытай һәм башка илләрнең керүе белән аңлатыла.

Хезмәткә төрле социаль төркемнәргә караган кешеләрне җәлеп итүне исә илдәге табигый демография һәм эшкә алуга бәйле дәүләт программаларының эшләве белән аңлатырга була. Әйтик, 30 яшькә кадәр яшьләрне җәлеп итү өчен субсидияләр бирү, 14–18 яшьлекләрне эшкә яллауга бәйле үзгәрешләр, илкүләм проектлар һәм башкалар.

Быел энергетика секторында тәкъдимнәр күп булачак. Яңа инфраструктура объектлары төзелә һәм файдалануга тапшырыла, энергетика өлкәсендә өйрәнүләр алып барыла. Әлеге өлкә белгечләренә зур компанияләр ягыннан да, кече бизнес ягыннан да сорау булачак.

Эш эзләүчеләргә килгәндә, монда да кызыксынулар төрле. Тулаем алганда, ил буенча 2022 елда кандидатлар вакансияләргә 28 процентка активрак җавап бирде. Иң зур үсеш «Тәҗрибәсе булмаган, студентлар» (+53 процент) һәм «Фитнес, матурлык салоны» (+38 процент) юнәлешләрендә.

Башкалада вазгыять бүтәнчәрәк. Эш эзләүчеләр 18 процентка артты. Потенциаль хезмәткәрләр өчен иң кызыклы тармаклар булып банк секторы (+78 процент) һәм административ эш (+59 процент) танылды.

27 гыйнвар сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Эльвира ВӘЛИЕВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Бу юлы укучыларыбыздан килеп ирешкән сораулар хокукый юнәлештә булды. Сорауларга «ВТ» юристы Булат ЗАКИРОВ җавап бирде.

Ташламалар бетәрме?

Мин – II группа инвалид. Ташламалардан файдаланам. Казанда фатирым бар. Арчада әбием бүләк итеп калдырган (дарственный) йортым да бар. Аны үземә рәсмиләштерсәм, ташламалар бетәчәк, диләр. Ничек итеп дөрес эшләргә?

АЗАТ

Җавап:
– Сораудан сүзнең нинди ташламалар турында баруы тулысынча аңлашылып бетми. Торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре өчен түләү ташламалары турында сүз барса, алар сезнең төп яшәү урыныгыз өчен сакланачак һәм сезнең мөлкәтегездәге башка күчемсез милек объектларына кагылмаячак. Шулай итеп, бер үк вакытта фатир һәм шәхси йорт өчен торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләренә түләү буенча ташламалар алып булмый.

Инвалидлык буенча бирелгән башка ташламалар гамәлдән чыгарга тиеш түгел. Һәр ташлама өчен төгәл аңлатмалар буенча дәүләт органнарына мөрәҗәгать итәргә киңәш бирәм.

Китсә, түлисеме?

Кызым «целевой» юллама белән укырга кергән иде. Тик менә укуы ошамый. Ташлыйм, ди. Әгәр дә укуыннан китсә, без акча түләргә тиеш булабызмы?

АЛСУ

Җавап:
– Әлеге сорауга төгәл итеп җавап бирү өчен, максатчан белем бирү турындагы шартнамәнең югары уку йортына максатчан кабул итү квотасы буенча керүне күздә тотканмы-юкмы икәнен аңларга кирәк.

Әгәр килешү вузга максатчан кабул итү квотасы буенча укырга керүне күздә тотса, мондый килешүне яклар ризалыгы буенча өзеп булмый. Гражданин килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җавап тота. Студент дәүләтнең ярдәм чараларын һәм уку чыгымнарын түләргә тиеш: болар – стипендия, уку бәясе.

Әгәр килешү вузга максатчан кабул итү квотасы буенча укырга керүне күздә тотмаган икән, килешү яклар ризалыгы буенча өзелергә мөмкин. Ризалыкны заказ бирүче һәм гражданин язмача рәвештә рәсмиләштерергә тиеш. Әгәр сез максатчан урыннарга түгел, ә гомуми конкурс буенча укырга кергәнсез икән, уку чыгымнарын капларга кирәкмәс.

Әгәр дә килешү башка ярдәм чараларын тәкъдим итүне күздә тотса, бу мәсьәләне шәхси тәртиптә җайга салырга кирәк.

Фатир тиешме?

Азнакай районының Тымытык авылында 1932 елның 20 гыйнварында туган әнием, хезмәт һәм тыл ветераны Рәсимә Сәлим кызы Шәрәфетдинова яши. Йорты иске, яшәү шартлары начар: түбәдән су үтә, социаль хезмәткәр суны күршеләрдән ташып интегә. Законда тыл ветераннарына дәүләт тарафыннан уңайлыклары булган бушлай торак бирү каралганмы? Андый мөмкинлек булса, кемгә мөрәҗәгать итәргә икән?

Рузилә ШӘРӘФЕТДИНОВА, пенсионер

«Гарант» юридик үзәк белгечләре:
– Хезмәт ветераннарына ташламалар түбәндәге норматив актлар нигезендә бирелә: 1995 елның 12 гыйнварына караган «Ветераннар турында» федераль законның 22 нче маддәсе; «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабренә караган Татарстан Республикасы законының 5 нче маддәсе; Татарстан Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы нигезләмәсе.

Гадәти пенсия яки дәүләт пенсиясе алучы хезмәт ветераннарына, айлык уртача кереме 20000 сумнан артып китмәсә, түбәндәге социаль ярдәм чаралары күрсәтелә:

– ай саен 200 сум күләмендә акчалата түләү;

– 60 һәм 55 яшьлекләргә (ир-атлар һәм хатын-кызлар) бушлай теш протезлау һәм ишетү аппаратлары ясату;

– телефон түләүләре өчен субсидия;

– торак өчен түләүгә киткән чыгымнарның 50 проценты күләмендә субсидия (Татарстан законнарында билгеләнгән торак мәйданы социаль нормасы чикләрендә);

– үзәк җылыту системасы булмаган йортларда яшәүче халык өчен хезмәт күрсәтүләрдән файдалануның билгеләнгән нормативлары чикләрендә коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә чыгымнарның 50 проценты күләмендә субсидия.

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, хезмәт ветеранына торак шартларын яхшырту Россиянең Торак Кодексы тарафыннан билгеләнгән гомуми тәртиптә мөмкин дип саныйбыз.

Редакциядән: мәсьәләне тулырак аңлату өчен, Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы «кайнар элемтә» номерына шалтыратырга мөмкин: **8-800-6 000 000, 557-21-12** (халык белән эшләү секторы).



pinterest.com

Кайчан түләрләр?

Медицина хезмәткәрләренә түләүләр булачак, дип ишеттем. Ул кемнәргә кагыла?

Кайбычтан укучыгыз

Редакциядән. Без бу хакта хәбәр иткән идек инде. Мәгълүм булганча, Россия Хөкүмәте яңа түләү турында карар кабул итте. Ул сәламәтлек саклау, район үзәк, район һәм участок хастаханәләренең беренчел звеносы медицина хезмәткәрләренә, шулай ук станцияләрдә һәм ашыгыч ярдәм бүлекләрендә эшләүчеләргә каралган. Татарстан буенча социаль фонд бүлеге февраль аенда медицина хезмәткәрләренә махсус түләүләр күчерә башлаячак. Белгечнең категориясенә һәм медицина оешмасының төренә карап, яңа ярдәм чарасының күләме 4,5 мең сумнан 18,5 мең сумга кадәр тәшкил итәчәк. Яңа түләү алу өчен бернәрсә дә эшләргә кирәкми. Акча медицина оешмасы хезмәткәрләр реестрын формалаштырганнан һәм тәкъдим иткәннән соң 7 көн дәвамында исәпләнәчәк.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Укучы сүзе

МАХСУС ХӘРБИ ОПЕРАЦИЯГӘ КИТКӘН ҖЫРЧЫ ТАҺИР АСЫЛГӘРӘЙ ТУРЫНДА ЯЗМАГА КАЙТАВАЗ

Берүк исән-сау кайта күрсен. Шалтыратып торса, «мин исән» дисә, шуннан да зур шатлык юк. Минем дә туганымны алдылар бит. Бер кайгысыз кеше юктыр бу дөньяда.

Мәгъфирә ЗАКИРОВА

СУ СЫЙФАТЫНА БАГЫШЛАНГАН ЯЗМАГА КАЙТАВАЗ

Авылда торсак та, чишмә суы юк. Чишмәләр бик еракта калды. Элек көянтә белән ташый идек, хәзер колонка суы эчәбез. Әле су бетеп аптыратмый, куанып торабыз шуңа. Машиналы кешеләр ерактан да алып кайта.

Нурания САБИТОВА

ИНТЕРНЕТТА ТАНЫЛГАН ХИФФӘ ӘБИГӘ БАГЫШЛАНГАН ЯЗМАГА КАЙТАВАЗ

Хиффә әбине бик юксындым. Үземнең әниемә охшатам. Рәхмәт сезгә аны күрсәткәнегез өчен. Исәнлектән аермасын Хиффә әбине! Ялгыз моңаерга ирек бирмиләр әбигә. Һәрвакытта да булышып торалар, ярдәменнән ташламыйлар.

Фәния ХӘЙБУЛЛИНА

ИФИРА САЙБАТАЛОВА ТУРЫНДА ЯЗМАГА КАЙТАВАЗ

Ул геннардан килә, фигура саклау да, кыяфәт тә. Безнең әнкәй беркайчан физкультура ясамады, диетаның ни икәнен белмәде, санаторийларның ишеге кайсы якка ачылганны да, нинди булганын да белмәде. Гомер буе кара яндырып чәй эчте, кара итеп яса, дип әйтә торган иде. Ипи яратып ашый иде. Бөтен нәрсәне дә ипи белән ашады. Гомер буе тозлы әйберләр яратты. Бер операция дә кичермәде, күзлексез укыды, 95 яшендә аппетит белән ашап, үз аягында йөреп, картлык чире белән үлеп китте. Аллаһы Тәгалә гомерне, сәламәтлекне бирә икән, бернәрсәгә дә карамый.

Розалия ДИЛЬМИЕВА

23 гыйнвар | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 15.30 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». Телесериал 12+
10.00, 23.00 «ОТРЯД». Телесериал 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «КӨЗГЕ ЧӘЧӘКЛӘР». Телесериал 12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество»16+
14.45 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.30 «Татарлар» 12+
17.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Трактор» – «Ак барс». Прямая трансляция 0+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Соотечественники» 16+
00.45 «Каравай». Красота русского пейзажа 6+
01.10 «Таяну ноктасы» 16+
01.35 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Яшьлегем хисләре». Венера Ганиева җырлый 6+
12.05, 18.20, 21.25 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». Телефильм 16+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.55, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Большая премьера. Основано на реальных событиях. Многосерийный фильм «НУЛЕВОЙ ПАЦИЕНТ» (S) 16+
22.40 «Большая игра» 16+
00.00 Светлана Ходченкова, Александра Ребенок, Анна Банщикова, Сергей Бурунов. «КРАТКИЙ КУРС СЧАСТЛИВОЙ ЖИЗНИ» (S) 18+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Максим Аверин. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Елена Яковлева в телесериале «КАМЕНСКАЯ»
03.50 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Профессиональный бокс. Фёдор Папазов против Акжола Сулайманбека Уулу. Трансляция из Екатеринбурга 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 15.50 Новости
07.05, 19.15, 21.30, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00 Специальный репортаж 12+
10.25 Смешанные единоборства. INVICTA FC. Таниша Теннант против Талиты Бернардо. Трансляция из США 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «География спорта. Рязань» 12+
13.50 Матч! Парад 16+
14.25 Спортивный дайджест 0+
15.55 «Громко» Прямой эфир
16.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Металлург» (Магнитогорск) – «Барыс» (Астана). Прямая трансляция
19.55 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. ЦСКА – «Астраханочка» (Астрахань). Прямая трансляция.
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Интер» – «Эмполи». Прямая трансляция.
01.35 Конный спорт. Скачки. Трансляция из ОАЭ 0+
03.30 Новости 0+
03.35 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. ЦСКА – «Астраханочка» (Астрахань) 0+
05.05 «Громко» 12+

НТВ

04.50 Детективный сериал «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. ВОЗВРАЩЕНИЕ» (S) 12+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Исторический детектив «БЕЗСОНОВЪ» (S) 16+
22.10, 00.00 Остросюжетный сериал «ЧУЖАЯ СТАЯ» (S) 16+
00.40 Остросюжетный сериал «ЧУМА» (S) 16+
03.05 Сериал «БОМБИЛА. ПРОДОЛЖЕНИЕ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.40 «Давай разведёмся!» 16+
09.40 «Тест на отцовство» 16+
11.55 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Статуэтка» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «ДОМ НА КРАЮ ЛЕСА» 16+
19.00 «ПЕРЕВОД НЕ ТРЕБУЕТСЯ» 16+
22.50 «Порча» 16+
23.25 «Знахарка» 16+
00.00 «Верну любимого» 16+
00.30 «Понять. Простить» 16+
01.30 «Тест на отцовство» 16+
03.15 «Давай разведёмся!» 16+
04.05 «6 кадров» 16+
04.10 «НАПАРНИЦЫ» 16+
05.00 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

03.55 «ВНИМАНИЕ, ГОВОРИТ МОСКВА!» 1-я – 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня. 16+
09.15 «ВОЛГА-ВОЛГА» 6+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.40, 15.05 «МАРШ-БРОСОК. ОХОТА НА «ОХОТНИКА» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Документальный сериал. Витебск 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «Ленинград. Блокада» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «БЕЗ ОСОБОГО РИСКА» 12+
01.00 «ВТОРЖЕНИЕ» 12+
02.30 «Блокада. День 901-й». Документальный фильм 12+
03.20 «Военные врачи. Военный врач Александр Сахаров. Вера длиною в жизнь». Документальный фильм 16+
04.00 «АНАКОП». 1-я и 2-я серии 16+

24 гыйнвар | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». Телесериал 12+
10.00, 23.00 «ОТРЯД». Телесериал 16+
11.00 «Азбука долголетия» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «КӨЗГЕ ЧӘЧӘКЛӘР». Телесериал 12+
13.00 «Татар халык җырлары» 0+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Казаннан – Казанга» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Чёрное озеро» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». У истоков жизни. В.С. Груздев 16+
00.40 «Каравай». Живет в народе красота 6+
01.05 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Ком сәгате» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». Телефильм 16+
15.30 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.55, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «НУЛЕВОЙ ПАЦИЕНТ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.40 «Большая игра» 16+
00.00 «КРАТКИЙ КУРС СЧАСТЛИВОЙ ЖИЗНИ» (S) 18+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Максим Аверин. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Елена Яковлева. «КАМЕНСКАЯ»
03.50 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 18.20 Новости
07.05, 14.25, 20.00, 22.30, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00 Специальный репортаж 12+
10.25 Смешанные единоборства. Strikeforce. Лучшее 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «Что по спорту? Казань» 12+
13.50 «Здоровый образ. Хоккей» 12+
16.25 «География спорта. Рязань» 12+
16.55 Еврофутбол. Обзор 0+
17.50 «Ты в бане!» 12+
18.25 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Мужчины. «Чеховские медведи» (Московская область) – СКИФ (Краснодар). Прямая трансляция
20.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Шальке» – «Лейпциг». Прямая трансляция
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Лацио» – «Милан». Прямая трансляция
01.35 Футбол. Чемпионат Германии. «Бавария» – «Кельн» 0+
03.30 Новости 0+
03.35 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Мужчины. «Чеховские медведи» (Московская область) – СКИФ (Краснодар) 0+
05.05 «Виктор Царёв. Капитан великой команды». Документальный фильм 12+

НТВ

04.50 Детективный сериал «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. ВОЗВРАЩЕНИЕ» (S) 12+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Исторический детектив «БЕЗСОНОВЪ» (S) 16+
22.10, 00.00 Остросюжетный сериал «ЧУЖАЯ СТАЯ» (S) 16+
00.55 Остросюжетный сериал «ЧУМА» (S) 16+
03.10 Сериал «БОМБИЛА. ПРОДОЛЖЕНИЕ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.40 «Давай разведёмся!» 16+
09.40 «Тест на отцовство» 16+
11.55 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «У колыбели» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «ГДЕ ЖИВЁТ НАДЕЖДА?» 16+
19.00 «ТОНКАЯ РАБОТА» 16+
22.50 «Порча» 16+
23.25 «Знахарка» 16+
00.00 «Верну любимого» 16+
00.30 «Понять. Простить» 16+
01.30 «Тест на отцовство» 16+
03.15 «Давай разведёмся!» 16+
04.05 «6 кадров» 16+
04.20 «НАПАРНИЦЫ» 16+
05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «АНАКОП». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 01.00 «ЖИВЕТ ТАКОЙ ПАРЕНЬ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 18.20 «Специальный репортаж» 16+
14.05, 15.05 «ГЛАВНЫЙ КАЛИБР». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.55 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Документальный сериал. «Малая земля» 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «713-Й ПРОСИТ ПОСАДКУ» 12+
02.40 «БЕЗ ОСОБОГО РИСКА» 12+
03.55 «ГЛАВНЫЙ КАЛИБР». 1-я и 2-я серии 16+

ПЛЭЙ-ОФФКА КҮП КАЛМАДЫ

«АК БАРС» КАЙЧАН КЕМГӘ КАРШЫ УЙНЫЙ?

20.01.2023	«Ак барс» – «Авангард»
23.01.2023	«Трактор» – «Ак барс»
25.01.2023	«Салават Юлаев» – «Ак барс»
27.01.2023	«Металлург» Мг – «Ак барс»
29.01.2023	«Ак барс» – «Трактор»
01.02.2023	«Ак барс» – «Барыс»
03.02.2023	СКА – «Ак барс»
05.02.2023	«Куньлунь Ред Стар» – «Ак барс»
07.02.2023	«Нефтехимик» – «Ак барс»
09.02.2023	«Ак барс» – «Амур»
14.02.2023	«Адмирал» – «Ак барс»
16.02.2023	«Адмирал» – «Ак барс»
18.02.2023	«Амур» – «Ак барс»
19.02.2023	«Амур» – «Ак барс»
24.02.2023	«Ак барс» – «Металлург» Мг
26.02.2023	«Ак барс» – «Авангард»

Белдерү

Кадастровым инженером Кутдусовой Натальей Генадьевной (СНИЛС № 128-830-216 57), являющейся членом СРО АКИ «Поволжье» (номер в реестре СРО «0182», дата вступления 05.07.2013 г.), квалификационный аттестат № 16-11-417, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1, адрес электронной почты: m2405085@yandex.ru, тел.: 8(843)2405085, в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:16:000000:6192, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Высокогорский муниципальный район, Чепчуговское сельское поселение, тер. СНТ «Калининец», з/у 391, выполняются кадастровые работы по уточнению границ и площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Ефимова Е.А. (тел.: +79656107949). Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования границ состоится по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1 21 февраля 2023 г. в 10.30 минут. С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1. Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с ежедневно с 9.00 до 17.00 часов с 1 февраля 2023 г. до 21 февраля 2023 г. по адресу: 420129, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1.

Смежный земельный участок с правообладателем, которого требуется согласовать местоположение границ:

– расположен по адресу: Республика Татарстан, Высокогорский муниципальный район, Чепчуговское сельское поселение, тер. СНТ «Калининец», з/у 393.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

АЙ СУЛЫШЫМ, ВАЙ СУЛЫШЫМ!

Һава җитми! Каядыр соңга калмас өчен йөгергәндә йә булмаса өске катка җәяү менгәндә, бу сүзләрне еш кабатларга туры килә. Әмма кайберәүләр бернинди физик авырлык килмәгән вакытта да һава җитмәүдән интегә. Ул ни сәбәпле килеп чыга? Һава җитмәү нинди авыруларның билгесе булырга мөмкин?

Казандагы Тимер юлчылар хастаханәсенең терапия бүлеге башлыгы Ләйсән ШӘЙХУЛЛИНА сорауларыбызга ачыклык кертте.

Нидән гыйбарәт? Халык телендә тын кысылу дип йөртелгән һава җитмәү күренеше медицинада диспноэ дип атала. Авыр физик эш башкарганда яки чамадан тыш хәрәкәтләнгәндә, тынчу бүлмәдә тын кысылу – гадәти күренеш. Әмма башка очракларда ул җитди авыру билгесе дә булырга мөмкин. Аерым алганда һава җитмәү түбәндәге чирләр турында кисәтә ала.

✷*Йогышлы авырулар*. Билгеле булганча, йогышлы авырулар вакытында тән температурасы күтәрелә, организм вируслар белән агулана, нәтиҗәдә сулау кыенлаша.

✷*Үпкә авырулары (пневмония, бронхиаль астма, бронхит, яман шеш, коронавирус)*. Сулыш алу бронхлар һәм үпкә шешү, ялкынсыну аркасында да авыраерга мөмкин.

✷*Йөрәк-кан тамырлары авырулары* вакытында кан әйләнеше акрыная, үпкәләр кыенрак эшли башлый. Һава җитмәү – ишемик йөрәк авыруының да төп билгесе.

✷*Азканлылык (анемия)*. Канда тукымаларга кислород алып килүче эритроцитлар кимесә дә кеше һава җитмәүдән интегә. Анемия, гадәттә, күп кан югалту, организмга тимер, B_{12} витамины, фолий кислотасы җитмәү аркасында барлыкка килә.

✷*Нерв системасы авырулары*. Тын кысылу таркау склероз, миастения, неврастения, психик тайпылыш билгесе дә булырга мөмкин.

✷*Эндокрин система авыруларының* да төп билгеләренең берсе ул тын кысылу. Әйтик, шикәр чире вакытында, калкансыман биз гормоннары чамадан тыш күп бүленеп чыкканда, кеше һава җитмәүдән интегә. Бу алда телгә алган күренешләр вакытында йөрәк тибеше үзгәрүгә бәйле.

✷*Йөклелекнең икенче, өченче триместрында* тын кысылу да – гадәти күренеш. Карындагы бала зурайган саен, ул эчке органнарга баса башлый. Шуңа күрә хатын-кыз еш кына йөргәндә генә түгел, йоклаганда да һава җитмәүдән тилмерә. Андый чакта сулыш алу күнегүләре хәлне җиңеләйтә.

Кайчан табибка мөрәҗәгать итәргә? Һава җитмәү кисәк кенә борчый башласа, кичекмәстән табибка күренергә кирәк. Шуның белән бергә кешенең иреңе, бармаклары зәңгәрләнсә, күкрәк читлеге авыртса, йөрәк тибеше ешайса, тән температурасы күтәрелсә дә кичекмәстән белгечкә мөрәҗәгать итәсе. Сулыш алганда сызгырган тавыш ишетелсә дә чаң сугарга җирлек бар. Һава җитмәгәндә тубык сөяге, табан турысы шешеп чыкса да тиз арада табибка күренергә кирәк.

Ничек дәвалана? Һава җитмәүнең ни сәбәпле булуына бәйле рәвештә, аны физик күнегүләр, ингаляция һәм дарулар, кислород терапиясе ярдәмендә дәвалыйлар.

Үзлегеңнән хәлне ничек җиңеләйтергә? Һава җитмәгәндә иң элек буяу, машинадан чыккан газ кебек химик матдәләр иснәүдән саклангыз. Алар үпкәләрне ярсыта. Тәмәке тартудан баш тарту да хәлегезне җиңеләйтәчәк. Һава температурасы артык югары һәм артык түбән булганда, актив хәрәкәтләнергә кирәкми. Гәүдә авырлыгы да һәрчак контрольдә булсын. Һава җитмәгәндә, махсус сулыш алу күнегүләре дә ярдәм итә.

ҺАВА ҖИТМӘГӘНДӘ СУЛАУ КҮНЕГҮЛӘРЕ

✓Тирән итеп сулыш алганда, дүрткә кадәр санагыз. Сулышны тоткарлап, сигезгә кадәр санагыз. Аннары, шулай ук сигезгә кадәр санап, һаваны авыз аша кире чыгарыгыз. Әлеге күнегүне башкарганда иреннәр сызгыргандагы кебек халәттә булырга тиеш. Күнегүне берничә тапкыр кабатларга кирәк.

✓Тирән итеп, борын белән сулыш алганда, дүрткә кадәр санагыз, бер үк вакытта кулларны алга чыгарып, өскә күтәрегез. Аннары авыз аша һаваны акрынлап кире чыгарыгыз. Һаваны кире чыгарганда, учларны аска каратып, кулларны ян-якка төшерергә кирәк.

Лимфа бизләрен чистарту

Лимфа бизләренә организмдагы барлык әгъзаларның, барлык тукымаларның эшчәнлеге бәйле икән. Организмнан токсиннар, шлаклар нәкъ шул лимфа бизләре хисабына чыгарыла да инде.

➤Гөлҗимеш төнәтмәсе лимфа бизләрен чистартырга ярдәм итә.

➤Тырнак гөл (календула) төнәтмәсе дә бик яхшы чистарткыч булып тора. 10 г тырнак гөлгә 1 стакан кайнар су салып, 20 минут су мунчасында тотыгыз. Шуны суытып сөзегез дә яртышар стаканлап көнгә 3–4 тапкыр эчегез.

➤Бизләрне шулай ук кара карлыган яфрагыннан, җимешеннән ясалган төнәтмәләр дә нәтиҗәле чистарта. Әлеге төнәтмә шулай ук бөер һәм кан тамырлары тышчасын чистартырга ярдәм итә. Ул тырнак гөл төнәтмәсе шикелле үк ясала. Аны да, яртышар стаканлап, көнгә 3–4 тапкыр эчәргә кирәк.

➤Организмны лимфа системасы аша шулай чистарту курсы ике атнага исәпләнгән. Моның өчен, беренче көннән башлап, 8–10 көн дәвамында, иртәнге ашка 30 минут кала, бер стакан кайнаган су белән активлаштырылган күмер эчәргә кирәк. Күмер токсин калдыкларын эшкәртергә ярдәм итә. Ә дәвалау курсы алдыннан ике атнага майсыз, камырсыз, ысланган ризыксыз һәм итсез диетага күчәргә кирәк.

КАН БАСЫМЫН ТӨШЕРӘ

Бәрәңге кан басымын нормальләштерергә ярдәм итүче калий белән магнийга бай. Моннан тыш, уртача зурлыктагы бәрәңге нибары 150–160 калориягә генә ия. Кан басымын төшерү өчен, кабыклы бәрәңгене суда йә томалап пешерегез. Йогырт кушып ашасагыз, икеләтә файдалы булачак.

Какао. Австралия галимнәре фикеренчә, табигый какао порошогы булган ризыклар кан басымын түбәнәйтә. Чөнки составындагы флавоноидлар кан тамырларының торышын яхшырта. Какаоның калориясе күп. Шуңа күрә аны көнгә 1 аш кашыгыннан артык кулланырга ярамый.

Ногыт борчагы. Кузаклы үсемлек клетчатка, магний һәм калийга бай. Һәр көнне ногыт борчагы, борчак ясмык ашарга гадәтләнәсез икән, сезне кан басымы борчымаячак.

Банан. Калий чыганагы булып тора. Банан тозның да зыянлы йогынтысын бетерә. Өлкәннәргә көн саен 4,7 грамм калий кирәк. Ә бер бананда киңәш ителгән норманың 12 проценты бар. Аны иртән боткагызга салыгыз, я булмаса түгәрәкләп кискәләп, киптерегез. Тәмле десерт та булачак, кан басымыгыз да төшәчәк.

ТЕШ СЫЗЛАГАНДА, НИЧЕК АВЫРТУНЫ БАСАРГА?

Теш сызлаганда, табибка барганчы авыртуны ничек басарга?

▶Теш сызлый башлагач, тиз генә табибка күренү мөмкинлеге булмаса, авызны бер стакан җылы суга бер бал кашыгы сода салып чайкатырга.

▶Теш сызлавын гап-гади канәфер басарга мөмкин. Аны авырткан теш белән чәйнәп, уртка кысарга кирәк. 15 минуттан авырту басылырга тиеш.

▶Авыз эчен эвкалипт, ромашка, шалфей, бөтнек төнәтмәләре белән чайкасаң да файдасы зур.

▶Камфора, ак чыршы, канәфер маена мамык йисә марляны манып, 15 минутка сызлаган тешкә куярга кирәк.

Ашказаны авыртканнан солы кесәле

Солы кесәле ашказаны, бавыр һәм бөер өчен файдалы. Ул үт һәм бөер ташларын эретә, кандагы холестеринны киметә. Әлеге кесәлне ясау өчен 1 стакан солы ярмасы, 5 стакан су, 1 стакан сөт, 3–4 кашык бал кирәк. Башта солы ярмасына су салып, кесәлгә әйләнгәнче сүрән утта пешерәбез. Аннары сөт өстәп, берничә минут утта тотабыз. Беразсуынгач, бал өстәргә була. Көн дәвамында кесәлне үзегез теләгәнчә ашагыз. Бу файдалы ризык организмны чистарта. Дөрес тукланмау аркасында еллар дәвамында җыелган зарарлы матдәләрдән котылырга ярдәм итә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

ОРЛЫКНЫ КЫШТАН ӘЗЕРЛИСЕ

Урамда әле гыйнвар суыклары хөкем сөрсә дә, бакчачылар «селкенә» башлады инде. Алар сыйфатлы орлык юнәтү белән мәшгуль хәзер. Махсус кибет киштәләре селекция могҗизасына тиң яшелчә рәсемнәре сурәтләнгән орлык каплары белән тулган. Әмма бер генә сатучы да бакчачылар өметенең ничегрәк акланасын әйтә алмый.

Күзен мул уңышка сөенеп туя алмас өчен нәрсә чәчәсен «Россельхозцентр» оешмасының Татарстан буенча филиалы җитәкчесенең орлыкчылык буенча урынбасары Рафис Рамил улы ХӘБИБУЛЛИНнан сораштык.

Белгеч әйтүенчә, Россиядә, закон нигезендә, Селекция казанышлары дәүләт реестрына (государственный реестр селекционных достижений) кертелгән орлыкларны гына сату рөхсәт ителә. Ил өчен бердәнбер ул. Әмма һәрбер орлык яки үсенте ниндидер төбәккә яраклаштырып әзерләнелә. Мәсәлән, Төньяк Кавказ төбәгендә үстерү өчен чыгарылган орлыкның бездә – Идел-Нократ төбәгендә ниндидер уңыш бирүе икеле. Әмма орлык җитештерүчеләр, гадәттә, теге яки бу культураны кайсы төбәктә үстерүнең кулайрак булуын күрсәтми. Шуңа күрә орлыкларның дәүләт реестрыннан үзегезгә ошаган сортның кайсы төбәккә яраклаштырып чыгарылуын карау һич тә зыян итмәячәк.

Рафис Хәбибуллин орлык сайлау буенча киңәшләрен дә бирде. Орлыкларны үзегез белгән яки тәҗрибәле бакчачылар киңәш иткән махсус кибетләр яки фирмалардан гына сатып алыгыз. Шунысын истә тотарга кирәк: яхшы орлык беркайчан да арзан була алмый. Кемнәрдәндер бәясе төшерелгән орлыклар алмагыз, «ташлама», «акция»ләрне дә читләтеп узыгыз. Гадәттә, куллану вакыты чыгарга озак калмаган, киштәдә байтак вакыт аунап яткан сыйфатсыз товарны гына ташлама белән саталар. Орлык сайлаганда, кабының матурлыгына түгел, ә җитештерүчесе турында мәгълүматка игътибар итегез. Шулай ук бер төрле генә сорт яки бер төрле генә җитештерүченең орлыгын сатып алмагыз. Төрлесеннән алсагыз, сортка да, җитештерүчесенә дә тиешле бәя бирә алачаксыз.

vk.com

Белгеч берочтан «гибрид» һәм «сорт» төшенчәләрен дә тагын бер кат аңлатып үтте. Орлык кабында F1 дип язылган икән, димәк, гибрид (ике яки аннан күбрәк сортны кушып ясалган орлык) бу. Мондый орлыктан үстерелгән культура чирләргә бирешмәве, суыкка чыдам булуы, мул уңыш бирүе белән аерылып тора. Гибрид орлык кабына, әйтик, помидорларның авырлыгы 500 граммга җитә, дип язылса, чыннан да, моңа ышанырга мөмкин. Ә менә гадәти сорттан, бик тырышып үстергәндә дә, мул уңыш алу кыен.

Орлык кабындагы мәгълүматларга килгәндә, партия номеры һәм капка тыру вакытының нинди ысул белән басылуы гына да күпне сөйли, ди Рафис Рамил улы. Типографик ысул белән басылган икән, орлыкның фальсификат булып чыгу куркынычы зур. Ник дигәндә, типографиядә басканда, кайсы капка нинди партиянең һәм кайчан тутырылачагын белеп булмый бит.

Белгеч саклагыч тышча белән капланган гранулалы орлыкларның өстенлекләрен дә аңлатып үтте. Беренчедән, мондый орлыкларны ара калдырып утырту җиңел. Икенчедән, туклыклы матдәләргә бай булган катлам белән тышлану нәтиҗәсендә, тизрәк шытып чыга, авырулар һәм корткычларга бирешми. Шул ук вакытта гадәтиеннән 10–25 процентка күбрәк уңыш бирә. Утыртыр алдыннан мондый орлыкларны суда тотмыйлар, чөнки саклагыч тышчасы эреячәк.

Әлфинур НӘҖМЕТДИНОВА, һәвәскәр бакчачы:
– Бакчачылар, гадәттә, мул уңыш бирүче һәм әйбәт сакланучы яшелчә сортларын хуп күрә. Безнең якларда, әйтик, кишернең «нантская», «лосиноостровская», «самсон» сортлары әйбәт үсә. Кыярдан – «родничок» (тозлау-маринадлау өчен уңайлы) һәм «зозуля» (җәйге салатлар ясау өчен) кебек сортлардан да яхшырагы уйлап табылмагандыр әле, дип уйлыйм. Помидорга килсәк, бүген яңа, моңарчы күз күрмәгән-колак ишетмәгән сортларны эзлибез. Күпләр сары яки шоколад төсендәге помидорлар утырта. Язылмаган кагыйдә буенча, теплицада помидорның берничә сорты: салат ясау һәм маринадлау өчен кулай булган кимендә берәр сорт үсеп утырырга тиеш.

Укучы киңәше

Кышын салат үстерәм

Элегрәк, кибеттән сатып алынган пластик чүлмәктәге салат үсентесен, яфраклары беткәч, туфрагы-ние белән чүплеккә ыргыта идем. Хәзер болай эшлим. Бүлмә температурасындагы кар яки яңгыр суын үтә күренмәле зуррак савытка салып, шуңа чүлмәкле салатны төрелмәсе-ние белән бергә 2/3 өлешкә батырам. Кояшлы тәрәзә төбенә куям.

Беренче 5–6 көн дәвамында әйбәтрәк яфракларына тимичә, начарракларын саклык белән генә кисеп алып, аш-суга кулланам. Су өстәп торам. Күчереп утыртырга әзерме-юкмы икәне яфракларыннан билгеле була. Ныгысалар, димәк, үсемлек минем шартларга ияләшкән, зуррак савытка күчереп утыртырга мөмкин, дигән сүз. Шиңгән яфракларын барысын да кисеп алам һәм, яңа тамырлары күренгәч (алар ак төстә була), күчереп утыртам.

Җептәй нәзек тамырларына зыян китермәс өчен, пластик савытның як-ягын кисеп, салатны туфрагы белән саклык белән генә алам да зуррак чүлмәккә тирән итмичә генә утыртам. Туфрак өстәп, су сибәм. Бер атнада – су (бер тапкыр), икенчесендә – сыек ашлама (чәчәк атмый торган үсемлекләр өчен) сибәм. Яңа үсеп чыккан яфракларны 30–40 көн дәвамында кисеп алып, кулланам. Күчереп утыртканнан соң 7–8 көн узгач, яңа салат алып, тагын шулай эшлим. Тегесен кулланганда, монысы үсә тора. Ай ярым узгач, салат яфракларына әчкелтем тәм керә, чәчәк угы барлыкка килә. Анысын инде ташлыйм.

Илсөя ШӘЙХЕТДИНОВА.
Казан

Тәмле булсын!

Кәбестә запеканкасы

Зөлфия ӘХМӘТОВА рецепты

Кирәк: *1 баш кәбестә, 1 кг ит фаршы, уртача зурлыктагы 3–4 баш суган, 2 телем икмәк, ярты стакан сөт, 3 аш кашыгы атланмай, тоз, тәмгә борыч.*

Икмәкне суга салып, 5–10 минут җебетәбез.

Суганны чистартып, иттарткыч аша чыгарабыз. Икмәкне судан алып, суын сыгабыз һәм кул белән йомшартабыз. Фаршка суган белән икмәк катнашмасын салып, әйбәтләп болгатабыз. Сөт өстибез. Тозлыйбыз, борычлыйбыз.

Тирән эчле табаның төбен атланмай белән майлыйбыз. Кәбестә яфракларын бер-берсеннән аерабыз. Таба төбенә бер катлам кәбестә яфракларын тезәбез. Өстенә – бер катлам фарш. Шулай итеп, фарш беткәнче, кәбестә яфракларын һәм фаршны, чиратлаштырып, катлам-лап урнаштырабыз. Өстенә кәбестә яфракларын тезеп калдырабыз. Табаны капкач белән каплап, 180 градуска кадәр җылытылган газ мичендә 30–40 минут пешерәбез.

Пешкәч, запеканканы кайнар килеш өлешләргә бүләбез. Табынга кайнар килеш тә, суынгач та куярга мөмкин.

Исеңдә тот!

ПЕСИ ТӘРТИПСЕЗЛӘНСӘ

Песиләр гөл чүлмәген актарырга яки анда йомышларын үтәп куярга да мөмкиннәр. Шулай икән, нарат күркәсе юнәтү ягын карагыз. Шуны гөл төбенә куйсаң, мәче аны әллә кайдан әйләнеп узачак. Чөнки ул нарат исен яратмый икән.

Ә инде песи баласы савыт кырыена пес итеп йөрсә, «күлләвек»кә тоз сибегез. Җебегәч, суга бераз йод салып, чүпрәк белән сөртеп алыгыз. Болай эшләгәндә, бернинди ис килмәячәк.

Белем тор!



ПИДЖАК ЯКАСЫ КЕРЛӘНСӘ

Керләнгән пиджак якасын 3 аш кашыгы суга 1 аш кашыгы нашатырь спирты салып ясалган эремә белән чистартырга мөмкин. Яка астына чиста салфетка урнаштырабыз, ә икенчесе белән, эремәдә чылатып, чистарганчы ышкыйбыз.

БЕР ВАКЫТ КЫНА

vk.com

Аны, тиз уза, дибез, җитми, дип зарланабыз. Ничек кенә булмасын, вакыт дигәнең тормышыбызда алыштыргысыз өлеш алып тора. Вакытны ничек җиткерергә? Аннан зарлану дөресме?

Вакытка бәйле сорауларыбызга Мөхәммәд хәзрәт МИФТАХОВ ачыклык кертте.

:: Хәдисләрдә вакыт, вакыт кадере турынданиләр әйтелә?

– Хәдисләрдә вакытка ишарәләр бик күп. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: «Аллаһы сөбханалла Тәгалә ул шул – кем сезне зәгыйфьлектә яратты», – ди. Монда балачак күздә тотыла. Аннан соң: «Зәгыйфьлектән сезгә көч бирә», – ди. Монда яшьлек турында сүз бара. «Аннары көчне зәгыйфьлеккә алыштыра», – диелә. Монысында инде картлык күздә тотыла. Пәйгамбәребез исә бер хәдисендә: «Минем өммәтемнең гомере алтмыш белән җитмеш арасында», – ди. Тагын бер хәдисендә ул: «Кеше күп вакыт Аллаһы Тәгаләнең ике нигъмәте турында оныта. Бу – саулык-сәламәтлек һәм буш вакыт», – ди. Бер мөхәддис: «Әй кеше, хакыйкате, син көннәрдән торасың һәм узган көнең белән синең гомерең дә уза», – ди. Пәйгамбәребезнең тагын бер хәдисендә исә: «Йә, адәм баласы, мин – синең өчен яңа көн һәм кыямәт көнендә мин синең өчен шаһит булачакмын. Шуңа күрә бүген изгелек кыл, иртәгә мин синең өчен шаһит булачакмын, бит мин бүтән беркайчан да кайтмам», – дигән юллар бар.

:: Бүген кеше күп вакытын интернетта уздыра. Моны вакытны бушка уздыру, сарыф итү дип санаргамы? Ул гөнаһ саналамы?

– Интернет ул – корал һәм бар да кешенең шушы коралны ни рәвешле, нинди максатта куллануына бәйле. Динебез һәр нәрсәдә алтын урталык саклау яклы. Интернет ярдәмендә уйнарга да, эшләргә дә була. Чама хисен генә югалтырлык булмасын. Әгәр интернетта утыруы кешенең Ходай Тәгалә, кешелек алдындагы бурычларын үтәүгә комачаулый икән, ул очракта бу тыела. Интернетта утыру вакытны исраф итү, гөнаһ саналачак.

:: Соңгы арада финанс, бизнес өлкәсендә яңа «таймменеджмент» дигән фән популярлашып китте. Ул туры мәгънәдә вакыт белән идарә итү фәне дип атала. Вакытны дөрес куллану өчен, адәм баласы нинди кагыйдәләрне истә тотарга тиеш?

– Хәзер «таймменеджмент» дип аталса да, чынлыкта безнең динебездә электәннән булган күренеш бу. Дин галимнәребез вакытның кадерен шул дәрәҗәдә белгән ки, аларда һәрбер нәрсә секундына кадәр язылган булган. Ул система һәрберебезнең тормышында булырга тиеш. Вакытны дөрес кулланырга өйрәнсәң, кая барырга, нәрсә эшләргә кирәген дә төгәл беләсең, тормышың да нәтиҗәлерәк булачак. Көн азагында планлаштырган эшләреңне тулысынча башкарып чыга алу-алмавыңа да нәтиҗә ясарга кирәк. Аллаһы Тәгалә безгә биш вакыт намаз уку бурычын да юкка гына йөкләмәгән. Кеше аның белән тормышын авырайта дип саный. Чынлыкта ул намаз ярдәмендә тормышын җиңеләйтә. Көнне дә биш өлешкә бүлеп, шул ук вакыт дигәнен дөрес һәм нәтиҗәле итеп уздырырга өйрәнә.

:: Ходай Тәгалә үлем сәгатен дә, никах сәгатен дә бер минутка алга да, артка да күчермәс дигән гыйбарә яши. Бу сүзне ничек аңларга?

– Моны шулай дип аңларга кирәк: «Аллаһы Тәгалә күпме гомер язган булса, кеше шулкадәр яши. Ул бер минут күбрәк тә, бер минут азрак та яшәмәс. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Әгәр адәм баласы үз ризыгыннан үлемнән качкан кебек качып йөрсә, үлем килгән кебек ризыгы да аңа шулай ук киләчәк», – ди. Шуңа күрә бу дөньяда күпме ризык алырга язган булса, кеше шулкадәр алачак та. Күбрәк тә түгел, азрак та түгел.

:: Яшерен-батырын түгел, көндәлек тормышта вакыттан зарланырга яратабыз. Вакыт җитми, вакыт тиз уза, вакыт табып булмый, дибез. Вакыттан зарлану дөресме?

– Пәйгамбәребез: «Вакыттан ләгънәт кылмагыз. Чөнки Аллаһы сөбханалла Тәгалә ул вакытны яратты», – ди. Шуңа күрә вакытны гаеп итәргә кирәкми. Вакыт ни өчен җитми? Чөнки без Аллах кушканча, дөрес яшәмибез. Аллаһка итагать иткән саен без бәрәкәткә ирешәбез. Аерым бер кеше генә түгел, бөтен җәмгыятебез дин кушканча яшәсә, тормышта гармония булачак. Ул чакта инде вакытның да, башка эш-гамәлләрнең дә бәрәкәте күренер.

Абау!

«АЛЛАҺ» СҮЗЕ ДӘВАЛЫЙ

Нидерланд психологы, профессор Ван дер Ховен Коръәни Кәримне уку һәм «Аллаһ» сүзен кабатлау барышында ачыш ясаган. Профессор бу ачышны өч ел буена күп кенә кешеләр белән алып барган тирән эзләнүләр тәҗрибәсе белән раслаган. Аңа ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән авыруларның күбесе мөселман булмый, кайберләре гарәпчә бер сүз дә белмәгән.

Дәвалау барышында аларга «Аллаһ» сүзен дөрес итеп әйтергә өйрәтәләр. Нәтиҗәсе барысын да гаҗәпкә калдырган. Әлеге сүз бигрәк тә төшенкелеккә бирелү һәм психик киеренкелектән азапланган кешеләргә уңай йогынты ясаган. «Коръәнне гарәпчә даими укучылар һәртөрле психик авырулардан имин була, чөнки анда «Аллаһ» сүзе күп мәртәбә кабатлана», – ди психолог.

Профессор «Аллаһ» сүзендәге һәрбер хәрефнең психик авыруларны дәвалаганда уйнаган ролен дә аңлата. Мәсәлән, «һәмзә» белән «әлиф», сулышны контрольдә тотып, тын юлларының эшчәнлеген яхшырта. «Ләм» сулышны җиңеләйтә. Ахыргы хәреф «һә» үпкә белән йөрәкне тоташтыра. Бу тоташу, үз чиратында, йөрәк тибешен тәртипкә сала икән.

Кыска фикердән күпне аңлау

Бер кеше Аллаһ Илчесе галәйһи вә сәлләм янына килеп: «Йә Рәсүлуллаһ! Сиңа Аллаһы өйрәткәннән миңа берәр нәрсә өйрәт әле», – дип әйткән.
Пәйгамбәребез галәйһи вә сәлләм бер сәхабәсенә мөрәҗәгать итеп: «Бу кешегә Коръәнне өйрәтегез», – дигән. Сәхабәләр әлеге кешегә «Зуллзилат» («Җир селкенмәк») сүрәсен өйрәтә башлаган. Алар сүрәнең болай дип әйтелгән соңгы аятенә килеп җиткәч («Кем дә кем (дөньяда) зәррә авырлыгы кадәр генә игелек кыла, аны (Ахирәттә) күрәчәк. Кем дә кем (дөньяда) зәррә авырлыгы кадәр генә начарлык кыла, аны (Ахирәттә) күрәчәк») бу кеше: «Булды. Миңа әлеге аятьләр җитә», – дип әйткән.
Моның хакта Рәсүлебез галәйһи вә сәлләмгә хәбәр ителгәч, ул: «Әлеге кешегә карагыз! Ул диндә фикһ белгече (тирән мәгънәләрне аңларга сәләтле булучы) булды», – дип әйткән.

(«Рухуль-Бәйан» китабыннан)

Йәгез, бер дога!

АШАР АЛДЫННАН УКЫЛА

Ашауны, һичшиксез, «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» дип башларга һәм түбәндәге доганы укырга кирәк:
«Әллааһүммә бәәрик ләнәә фииһи үә әтъгыймнәә хъайран минһ(ү).
Әллааһүммә әгътъыйнәә ризкъан хәләәлән үә әннтә хъайрур-раазикъыййн.
Әллааһүммә нәввир къулүүбәнәә үә-рхәмнәә үәрдъа гъәннәә.
Үә әгътъыйнәә тәмәәмә нигъмәтикә үә дәвәәмә нигъмәтикә үә тәмәәмә тәүфиикъыйк(ә)»

Мәгънәсе:
«Аллаһым! Ашларыбызга бәрәкәт бир, болардан да хәерлерәк ашларны ашарга насыйп кыл.
Аллаһым! Безгә хәләл ризык бир. Чөнки Син – ризык бирүчеләрнең иң хәерлесе.
Аллаһым! Күңелләребезне яктырт, безгә мәрхәмәт ит һәм бездән разый бул.
Узган гасырның 70–90 нчы елларында Купканың тирә-ягындагы авылларда әти-әниләр, улары тууга, җир алып, йорт салып куйган. Биредә исә аны төпләнеп каласы балага бергәләп җиткезгәннәр. Күрше авылда ягулык станциясе булдырган элеккеге укытучы Нурсил Шәймәрданов та тамырларны авылга беректерү турында еш уйлана икән. Эшмәкәрмен дип тормый, җирдә казынып, мал-туар асрап көн күрә ул. Хатыны Гөлнур белән өч ул үстерәләр. Ике уллары Янильдәге аграр көллияттә укый. Анда цифрлы җир эшенә, пилотсыз техникалар иярләргә өйрәнәләр.

> Авылга тартылу көчен тәрбияләү әти-әнидән тора. Авылда эш тә, бернәрсә дә юк, укып бетергәч, шәһәргә китү ягын карагыз, дип торганда, бала авылны ничек яратсын ди? Әти-әни бигрәк интеккән икән, шуңа күрә җибәрәселәре килә, дип уйлый бит ул.

– Балаларны район мәктәбенә йөртүче әти-әниләр дә бар. Алар ул-кызларын башлангыч сыйныфта үзебездә дә укыта ала бит, – ди Нурсил Шәймәрданов. – Бу – баланы авылдан аеру, шушы яшьтән үк аның авылга мөнәсәбәтен үзгәртү дигән сүз. Кукмарада яхшы, авылда начар укыталар, дигән фикер туа. Мин андый әти-әниләргә: «Сез үзегез тамырны өзәсез, соңыннан балагыз авылга кайтмаганга үкенәчәксез», – дим. Әгәр гөрләп торган авылның мәктәбен, клубын япсалар, кемнең каласы килсен? Таралган авылны яраттырып булмый.

Гөлназ Шәрәфиева: «Авылдан чыгып китүне күз алдына да китерә алмыйбыз».

Зөһрә САДЫЙКОВА

ХӘЛЕҢӘ КАРАП КЕРӘСЕ

Россиядә, шул исәптән Татарстанда да, «ярлылар өчен кибет»ләр популярлашып бара. Берничә дистә кибеткә якын киләчәктә тагын бер зур челтәр өстәләчәк. Әлеге кибетләрнең үзенчәлеге нәрсәдә дә, аларга кемнәр йөри? Бәяләр сыйфатка туры киләме? «ВТ» хәбәрчесе шундый кибетләрдә йөреп кайтты.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Авыл кешесе өчен шәп!

Дискаунтерлар халык телендә «ярлылар өчен кибет»ләр дип йөртелсә дә, сәүдә үзәгенә кергәндә керем буенча документларны сорамыйлар, әлбәттә. Бирегә төрле катлау кешеләре кереп, теләгән әйберләрен сатып ала ала. Товарларның аз ассортименты, аларның күпчелеге киштәләрдә түгел, ә идәндәге тартмаларда саклануы, персоналның аз, кибетләрнең склад тибында булуы һәм бәяләрнең, башка кибетләр белән чагыштырганда, 20–30 процентка түбәнрәк булуы. «Ярлылар өчен кибетләр»не аерып торган төп сыйфатлар менә шушы.

Әлеге вакытта Татарстанда дискаунтерлардан «Светофор», Smart, «Моя цена», «Доброцен», «Маяк», «Победа» һәм «Находка» кибетләре бар. Быел республиканың эре шәһәрләрендә X5 Retail Groupның дискаунтер форматындагы тагын бер челтәре – «Чижик» ачылырга тиешлеге хәбәр ителде. Аның беренчесен апрельдә Казанда ачмакчылар. Сайтларындагы мәгълүматтан аңлашылганча, Казан, Чаллы, Әлмәт шәһәрләрендә шундый 20ләп дискаунтер ачылырга мөмкин. Биредә үз сәүдә маркалары товарларын сатарга исәплиләр, шунлыктан бәяләр дә якынча 20–40 процентка арзанрак булачак дип ышандыралар. «Ни өчен арзан? Чөнки «Чижик» барлык чыгымнарны берләштерде. Сезгә ялыктыргыч рекламага, артык хезмәткәрләргә һәм чамадан тыш күп ассортимент өчен түләргә туры килмәячәк», – диелгән сайтларында. Моннан тыш, тиз бозылмый торган продуктлар идәндә тартмаларда торачак.

Дискаунтерның иң зур челтәре булган «Светофор» кибетләре бүген Татарстанның күпчелек районнарында эшләп килә. Әлеге вакытта 30дан артык кибет Казан, Чаллы, Яшел Үзән, Лаеш, Азнакай, Чистай, Алабуга, Балтач һәм башка район үзәкләрендә ачылган.

Балтачта яшәүче Рәсимә Гатиятуллина Кариле авылындагы «Светофор»га бик еш йөрүен әйтте. Атна-ун көнгә бер тапкыр чыгып, көнкүреш кирәк-ярагы, электр товарлары, ризыклар ала икән ул аннан.

– Бездә халык бик яратып йөри бу кибеткә. Авыл кешесе өчен менә дигән ул. Ишегалдына, сарай, бакчага чыкканда кияр өчен галошлар, аяк киемнәре, трикотаж өс киеме күп була анда. Бәяләре арзан, карап алганда, сыйфатлары да начар түгел. Уртача дип әйтик. Карап, составларын өйрәнеп алабыз, әлбәттә. Балык, консервлар алмаска тырышабыз. Сырлары да начар була. Ә менә үлән чәйләре яхшы. Печеньелар, катырылган яшелчәләре дә начар түгел. Бакча кирәк-яраклары да арзан. Мин үзем алмасам да, халык тавыкларын да яратып ала.

Районда «Фикс Прайс» кибетләре дә бар, аларга да йөрибез. Аннан күбесенчә ризыклар, канцелярия товарлары алына. «Шаром-даром» дигәне дә бар, тик аларында сыйфат начаррак, – диде ул.

Сыйфат сагайта

Андый кибетләр, билгеле, Казанда да шактый. Колакта яңгырап торган кибетләр булса да, моңа кадәр кереп, әйбер алганыбыз юк иде. Шуңа күрә барып, барысын да үзебез бәяләп кайтырга булдык.

Иң элек без Родина урамындагы «Светофор» кибетенә юл тоттык. Склад тибындагы бинада товарларның күпчелеге тартмаларда, капчыкларда идәндә саклана. Халыкны артык күп дип әйтеп булмый. Булганнары да – пенсионерлар. Берничә яшь балалы гаиләне дә очраттык. Без күнеккән кибетләрдән аерылып торган тагын бер сыйфаты – ассортиментның аз булуы. Халык арасында популяр булган чит ил брендларын монда очратам димә. Ризык маркалары, савыт-саба юу чаралары булсынмы – барысы да шәхсән минем өчен ят иде. Күп төрле йорт кирәк-яраклары, савыт-сабалар, юеш салфеткалар арасыннан яхшыларын алырга мөмкин. Ә менә ризыкларны бик карап, сайлап кына алырга кирәк. Бәяләре, чыннан да, арзанрак. Әйтик, «Кухмастер» маркасындагы томат пастасының 950 граммы 157 сум 20 тиен тора. 4 кг макаронны 198 сум 90 тиенгә алырга мөмкин, форель балыгының бер килограммы 479 сум 70 тиен тора. Көнбагыш майлары юк иде. Карабодай ярмасы да күзгә чалынмады.

Әлеге кибеткә даими йөрүчеләрне читтән карап та чамаларга мөмкин иде. Алар нәрсә аласын белеп, билгеле бер товар янына максатчан килә. Минем белән аралашып киткән Галя түти дә бер төрле сөт өстен (сливки) бик мактап, әрҗәсенә салып куйды.

– Мин монда гел йөрим. Вьетнам базары янындагысына да баргалыйм, чөнки анда сайлап алу мөмкинлеге зуррак. Тәртип, чисталык ягыннан да алдыра. Карарга күңелле. Товарларның бер өлеше киштәләргә урнаштырылган. Бу кибетләрдә бәяләр чыннан да арзан, шактый акчаны янга калдырып була. Менә карагыз әле, башка кибетләрдә дуңгыз итенең бер килограммы 300 сумга якын. Ә монда ул 199 сум гына. Мицелляр су бөтен кибеттә 150 сумнан башлана. Ә монда ул нибары 51 сум тора. Чәй эчәргә ак майлары да яхшы, – дип сөйләде.

Аның әйтүенчә, соңгы айда монда да сыйфат аксый башлаган. Әйтик, яхшы савыт-саба юу чаралары юкка чыккан. Хәзер сатыла торганнары начар, ди. Киптерелгән җимешләре дә күңелгә ятмады.

Икенче тукталышыбыз Smart кибете булды. Ул башкалада бер генә җирдә урнашкан. «Светофор»дан аермалы буларак, биредә товарлар гадәти кибетләрдәге кебек киштәләргә тезелгән, матур, иркен бинада урнашкан. Сатучылар үзләре дә әлегә халыкның күпчелеге «Светофор», «Находка»дагы кебек склад форматындагы дискаунтерларга йөрергә әзер булмавын әйтте. «Светофор» белән чагыштырганда, әлеге кибет күңелгә хуш килде. Биредә халык артык күп булмаса да, яшьләр булуы белән аерылып торды. Монда гадәти кибетләрдә сатыла торган барлык төр товарлар да бар. Барысының да бәяләре арзанрак дип әйтә алмыйм, чөнки чагыштырып бетерү мөмкин булмас иде. Ләкин халык арасында популяр булган кайбер төр товарлар, чыннан да, арзанрак шикелле тоелды. Әйтик, «Золотая семечка» маркалы көнбагыш маеның 1 литры – 109 сум 90 тиен, 750 граммлы «Кухмастер» томат пастасы – 134 сум 90 тиен, ике килолы «Макфа» оны – 118 сум, шикәр комының («Русский сахар») бер килограммы – 49 сум 80 тиен, карабодай ярмасының 700 граммы – 56 сум 90 тиен, «Сельский» ипие 47 сум тора. Моннан тыш, биредә сөт ризыкларының арзанрак булуына игътибар иттек.

Юрганыңа карап

Белгечләр әлеге кибетләр артуның төп сәбәбен халыкның керемнәре төшү һәм акчаны янга калдырырга тырышу белән аңлата. Әйтик, 2017 елның сентябреннән 2020 елның сентябренә мондый кибетләрнең саны 25 процентка арткан. Шулай да «Магнит» компаниясе президенты һәм генераль директоры Ян Дюннинг бер интервьюсында әлеге фикер белән килешмәвен белдергән.

– Дискаунтер – ярлылар өчен кибет түгел ул, – дигән ул әлеге әңгәмәсендә. – Европада бу бизнес төрле катлау кешеләре белән эшли. Ягъни бирегә аз керемлеләр дә, байлар да йөри. Әлеге кибетләрдә халыкны товар тирәсендә хезмәт күрсәтү түгел, ә бәясе һәм сыйфаты кызыксындыра. Һәм Европада мондый кибетләр популяр. Билгеле, кайберәүләр, россиялеләр мондый форматка әзер түгел, дип әйтергә мөмкин. Аның өчен беренче урында бәя тора. Ләкин 20 ел Россиядә яшәвемне исәпкә алсак, мин – Россия кулланучысы, беренче чиратта, шул ук Европа сатып алучысы, дип ышандырып әйтә алам. Россиялеләр товарның кайда эшләнүенә зур игътибар бирә.

КФУның маркетинг кафедрасы мөдире, икътисадый фәннәр докторы Наталья Каленская фикеренчә дә, мини-супермаркетлар форматының киләчәге зур.

– Бу – бүген иң тиз үсүче сегмент, – диде ул. – Россия буенча караганда, барлык сатып алуларның 25 проценты нәкъ менә шушы форматка туры килә. Әлеге кибетләрдә товар күбрәк сатыла. Беренчедән, монда ассортимент аз һәм бәяләр кулай. Икенчедән, күбрәк өлкәннәр йөри, ә алар өчен мондый кибетләр уңайлы, чөнки алар өчен сайлап алу мөмкинлеге артык мөһим түгел. Яшәү өчен беренче чиратта кирәкле товарлар булса, шул җиткән. Бирегә төрле катлау кешеләре йөри, дисәләр дә, аз керемлеләр күбрәк сатып ала.

Ә статистика андыйларның республикада күп булуын сөйли. Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2022 елда республикадагы ярлылык дәрәҗәсе 6 процентны тәшкил иткән. Бу 240 мең кешенең кереме яшәү минимумыннан (исегезгә төшерәбез: быелның гыйнварыннан ул 12219 сумны тәшкил итә) кимрәк дигән сүз. 2023 елда әлеге күрсәткечне 5,7 процентка кадәр кыскарту планы куелган. Азык-төлек бәяләре дә бер урында гына тормый. Узган ел азык-төлек кәрзине, әйтик, «Магнит»та 12–15 процентка артты.

Татарстан Дәүләт Советында «КПРФ» фракциясе җитәкчесе Хафиз Миргалимов фикеренчә, мондый форматтагы кибетләр – аз керемле халыкның хәлен җиңеләйтүнең бер чарасы.

– Бәяләр бөтен тармакта да котырып үсә, ә хезмәт хаклары буенча без – илдә 37 нче, Идел буе округында – алтынчы урында. Пенсиянең минималь күләме буенча 14 субъект арасында унөченче урында торабыз, – диде ул. – Шуңа күрә федераль дәрәҗәдә закон кабул итеп, бәяләрне билгеле бер проценттан артмаска кирәк. Икенчедән, аз керемле кешеләргә социаль ашханәләргә кереп ашау мөмкинлеген бирүче махсус карталар булдыруны карарга кирәк. Ә мондый эшмәкәрләргә салымны азайтырга, ташламалар бирергә кирәк. Өченчедән, «Бәхетле», «Пятерочка» кибетләрендә пенсионерлар өчен мини форматтагы бүлекләр ачарга мөмкин бит. Даруханәләр белән дә шулай эшләргә була.

Билгеле, кем нинди кибеткә барып товар аласын хәленә һәм мөмкинлегенә карап үзе хәл итә. Тик гомум икътисадый вазгыятьне исәпкә алганда, киләчәктә дискаунтерларның халык арасында популярлыгы артыр шикелле.

Сатып алучылар ризык кибетләрен сайлаганда нәрсәгә игътибар итә?

(Сораштыруда катнашучыларга берничә сорауга җавап бирү мөмкинлеге каралган)



- Сәүдә йортының кайда урнашкан булуы – 64,5%
- Товарларның уртача яки түбән бәясе – 61%
- Бонус, ташламалар һәм даими акцияләр булу – 49%
- Киштәләрдәге ассортимент күләме – 57%
- Бинаның чиста булуы һәм гигиена, санитар таләпләрнең үтәлеше – 36,5%
- Продуктларның сыйфаты, яшелчә, җиләк-җимешләрнең күп һәм сыйфатлы булуы – 33,5%

«Ромир» холдингы уздырган сораштыру нәтиҗәләре

СИРИНӘ МОСТАФИНА: «ЯҢАДАН ЯШӘРГӘ ӨЙРӘНӘМ»

Яшисе килә! Биектауда гомер итүче 38 яшьлек Сиринә Мостафина әнә шулай ди. Тормышның якасына ябышкан ул. Язмыш төрлечә сынаса да, бирешмәгән үзе. 27 яшендә инсульт кичергән Сиринә бүген инде һәр адымына, сөйләшә, хәтта ризык йота алуына да сөенә. Сөенмәслек тә түгел шул. Ә бит ул чакта аның исән каласына беркем дә диярлек ышанмый. Әлеге сынау аны кемнең кем икәнен аңларга, яхшыны начардан аерырга өйрәтә.

Сиринә Мостафинаның шәхси архивыннан

– Әти-әнием хәзер Түбән Камада яшиләр. Әмма мин Казанда туганмын, – дип, үзе белән таныштыра Сиринә. – Мәктәпне бетергәч тә, финанс институтына укырга кердем. Шунда булачак ирем белән таныштым. Бишенче курста укыганда ук кияүгә чыккан идем. Ирем белән матур гына яшәдек. Тик язмыштан узып буламы соң? Бер дә уйламаганда, миңа инсульт булды. Ул вакытта салым инспекциясендә эшли идем. Комага киткәнмен. Табиблар бернинди өмет бирмәгән. Үзем сулый алмагач, мине аппаратка тоташтырганнар. Ашау-эчүем дә көпшә аша булган. Хәер, боларның берсен дә хәтерләмим. Табиблар һәм якыннарым сөйләгәннәрдән генә беләм.

Сиринә белән гаиләсе турында сөйләшәбез. Ачылып китми, күренеп тора: бу хакта сөйләшәсе килми. Яңа гына гаилә корган, яратып яшәгән мәлдә, кинәт кенә тормышы 180 градуска үзгәргән аның. Йөгереп йөргән, чая, чибәр хатын-кыз бер мизгелдә урын өстенә ятсын әле! Бик авыр була Сиринәгә. Ике елдан ирсез дә кала. Монысын да күтәрә. «Сәламәт иргә авыру хатын нигә кирәк?» – ди үзе. Бирешмәскә тырыша, көчле булырга өйрәнә. Тернәкләндерү үзәкләренә йөри. Әкренләп яңадан кашык тотарга, ашарга-эчәргә, үз-үзен йөртергә өйрәнә. Дөрес, әлегә аяклары бик тыңлап бетерми. Әмма ул өметен өзми.

Сиринәгә яшәргә өйрәнергә социаль хезмәткәр ярдәм итә.

– Надия минем иң якын кешемә әйләнде. Андыйлар башка юктыр ул. Иң авыр чакларымда да ул ярдәм итә. Без аның белән туганнардан да якынрак. Нинди генә хәл булмасын, иң беренче итеп, Надиягә шалтыратам. Аның килүен түземсезлек белән көтеп торам, – ди Сиринә.

Надия үзе дә Сиринәгә ярдәм итә алганына сөенә. Аңа карап, ул да тормышның ямен аңларга өйрәнә.

– Сиринә сеңлем кебек миңа. Аның белән шундый рәхәт. Без аның белән мәш киләбез. Икәү бергә бассейнга йөрибез, физик күнегүләр ясыйбыз. Мин аның үз аягында ныклап йөри аласына чын күңелемнән ышанам, – ди Надия.

Сиринә, тернәкләндерү үзәгенә баргач, рәсем ясарга өйрәнеп кайта. Надиягә бер әйтүе җитә, ул шундук бар кирәк-яракларны алып кайтып бирә. Ә Сиринә шулкадәр матур итеп рәсемнәр ясарга өйрәнә, бу сәләтенә үзе дә шакката хәзер. Көнозын пумала тотып утыру бушка китми. Шушы шөгыленнән соң ул бәрәңге әрчи, савыт-сабалар юа башлый.

– Күңелемә тынычлык табу өчен дингә килдем. Язмышыма инде күптән үпкәләмим. Хәзерге тормышымнан рәхәтлек табарга өйрәндем. Ничек кенә тырышсам да, элеккеге Сиринә була алмам инде. Әмма үземне бәхетсез дип санамыйм. Якын дусларым бар. Аларның җылы карашыннан да хәлем рәтләнә кайчак. Элеккеге ирем дә хәлемне белеп тора. Кайчак йомышым булса, аңа әйтәм. Хатыны белән ике бала үстерәләр. Бәхетле яшәсеннәр, – ди Сиринә. – Россия ислам университетына укырга кердем. Урын өстендә генә ятсам да, бернишләп булмый. Мине аякка бастырган өчен Аллаһы Тәгаләгә чиксез рәхмәтлемен. Шушы яшемдә язмыш ничек кенә сынамады. Әмма яшәү теләге барыбер җиңеп чыга икән. Тырышырга кирәк. Үҗәт булсаң, авырлыкларны җиңә белсәң, бар да яхшы булачак. Янәшәдә чын дусларың булу кирәк. Алар барда авырып ятып булмый!

КЕШЕ ХӘЛЕН КЕШЕ БЕЛМИ, ҮЗ БАШЫНА ТӨШМӘСӘ

Азнакай районының Актүбә бистәсендә яшәүче Ләйлә Кәрамова белән сөйләшкәч, ирексездән шушы сүзләрне кабатлыйсың. Әгәр сынау арты сынау килмәгән булса, бәлки, Ләйлә дә, башкалар кебек үз тормышына сөенеп кенә яшәп ятар иде. Тик күңеле дә алай кушмый, әйткән нәзере дә бар аның.


Ләйлә Кәрамованың шәхси архивыннан

Моннан 32 ел элек беренче сабыен тапканда үлем белән күрешкәндә сүз бирә ул: «Исән калсам, бар гомеремне хәйриячелеккә багышлар идем!»

– Ул чакта Казан хастаханәсендә ятарга туры килде. Хәлем бик авыр иде. Реанимациядә чакта үз-үземә нәзер әйттем. «Кешеләргә ярдәм итеп яшәр идем», – дип гомер сорадым, – дип искә ала ул. – Өченче баламны тапканда да хәлем авырайды. Мин ул чакта комага киткәнмен. Озак ятарга туры килгән. Ирем Илдарга, хатының хастаханәдән исән кайтмас, дип тә әйтүчеләр табылган. Хәтта кызымны, үзем үстерәм, диюче дә булган. Тик ирем өметен өзмәгән. Мин комада чакта, үзенә декрет рәсмиләштереп, баланы караган. Әтисе үстерде инде ул кызымны. Элек күргәннәремне искә дә аласым килми. Даруга аллергия булу аркасында аңымны җуям мин. Кайчак икешәр көн ятам, кайвакыт озаграк та була. Азнакай табибларына рәхмәт, алар минем гомеремне саклап калу өчен барысын да эшли.

«Иң зур терәгем», – дип, ирен телгә ала Ләйлә. Өч баланы бергә аякка бастыралар, хәйрия эшләренә дә бергә тотыналар. Әле бит олы уллары Илнарга һәрвакыт игътибар һәм ярдәм кирәк. Әмма Кәрамовлар бирешмәгән: улларын аякка бастырырга тырышкан. Илнар спорт ярышларында катнашып, җиңүләр яулый икән. Уртанчылары Айсылу үз гаиләсе белән яши, кечкенәләре Рәзилә Лениногорск музыка көллиятендә белем ала.

Гаиләсе өчен күңеле тыныч Ләйләнең. Шуңа күрә башкаларга ярдәм итәргә теләп, районның инвалидлар оешмасын җитәкләргә алына. Үзләре дә авыр хәлдә калган, күп кенә борчу-хәсрәтләре булган, сәламәтлеккә тиенә алмаган кешеләрне бер учка җыя ул. Аларга тормышның якты ягы да барлыгын күрсәтергә тырыша. «Җырлы язмышлар» төркемен Азнакайда гына түгел, күрше-тирә районнарда да беләләр. Гомерләре буе сәхнәгә чыгарга хыялланган кешеләрнең теләген тормышка ашыра Ләйлә. Хәзер исә бергәләп мохтаҗларга ярдәм итү өчен хәйрия концертлары оештыралар.

– Районлагы авыру бала әниләре дә еш мөрәҗәгать итә. Барысына да булышырга тырышабыз. Мин инде төрләләр ишеген шакып керергә өйрәндем. Кешедән нидер сорау җиңел түгел. Әмма ярдәмгә мохтаҗ кешенең хәлен уйлыйсың да, үзеңнекен онытасың, – ди Ләйлә.

Актүбәдә урнашкан картлар йортын да үз канатлары астына алган алар. Анда яшәүче әби-бабайларның һәр гозерен ишетергә тырышалар. Аеруча коронавирус котырганда кирәк була Ләйләнең ярдәме. Даруларын да эзли, хәйриячеләрне дә барлый. Азнакайда белмәгән кеше юк аны. Күпләр изге күңеллелеген, кеше өчен җанын бирергә әзер булуын аңлаган инде. 2021 елда аңа Азнакай районы башлыгы Марсель Шәйдуллин карары белән «Ел хәйриячесе» исеме бирелгән.

Узган ел «Җырлы язмышлар»да җырлап йөрүче Ландышның ире өлешчә мобилизациягә эләгә. Солдатларга ярдәм итүләре дә шуннан башлана аларның. Азнакай Казан арасы да якын җир түгел. Әмма шуңа да карамастан, алар якташлары янына барып, «Казан Экспо»да биш тапкыр концерт куялар, егетләргә күчтәнәчләр тәяп киләләр.

– Төркемдәгеләргә рәхмәт! Авыру без, дип тормадылар, үзләреннән өлеш керттеләр. Ә бит, бер карасаң, алар үзләре дә ярдәмгә мохтаҗ. Тик көчле рухлы булулары аркасында алар башкаларны юатыр сүзләр тапты. Егет-кызларым үзләрен кызганганны яратмый, берәүдән дә ярдәм сорап та йөрмиләр. Киресенчә, үзләре кешеләргә булыша алуларына сөенеп торалар, – ди Ләйлә.

Декабрь уртасында Ләйлә тагын хастаханәгә эләккән. Йөрәге туктап калган аның. Аллаһы Тәгалә биргән гомере бетмәгән булган икән. Хастаханәдә өч көн ята да, дүртенчесендә табиблардан рөхсәт алып, янә Казанга юл тота.

– Таң атканны күрә алуым өчен генә булса да ниндидер изгелек эшлисе килә. Шуннан тәм табам, – ди Ләйлә. – Кайчак яхшылык эшләвемне аңламыйча, нахак сүзләр дә ишеттерүчеләр бар. Әмма андыйларга исем китми инде хәзер. «Әле дә син бар», – дип торучылар күбрәк чөнки. Алар көч бирә. Әгәр алай булмаса, әллә ничә кат «теге дөнья»дан кайтмас идем. Димәк, әле минем җирдә эшләнеп бетмәгән эшләрем бар.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

«ВТ» ГАЗЕТАСЫНЫҢ 105 ЕЛЛЫГЫНА МАХСУС ӘҢГӘМӘ.
БЕЗНЕҢ КУНАК – БУА ДӘҮЛӘТ ДРАМА ТЕАТРЫ СӘНГАТЬ ҖИТӘКЧЕСЕ, ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК АРТИСТЫ РАИЛ САДРИЕВ.

«МИНЕМ ХАКЫЙКАТЬ АКЧАГА КОРЫЛМАГАН»

Кыен хәлләр ныгыта гына. Буа театры җитәкчесе Раил САДРИЕВның тел төбендә әнә шул ята. Авырлыктан җиңеллек табучылар кайсы заманда да аз булгандыр ул, хәзерге заманда бигрәк тә тансык. Буш җирдә театр булдырган, аның 100 еллык тарихын язган, хәзер яңа театр төзеп яткан җитәкченең заманга, сәнгатькә карашы нинди? Юкка чыкмас өчен нәрсә эшләргә, кайсы илдә яшәү җиңел булачак? Әңгәмәдә – бу һәм башка сорауларга метафизик җавабы.

:: Казаннан читтәге театрларның һәрберсенең ниндидер бер «фишка»сы бар. Әлмәтлеләр үзләрен «фестивальщик»лар ди, мәсәлән, әтнәлеләр – авыл театры. Ә Буа театрының асылы нәрсәдә?

– Без – метафизиклар театры. Бер карага, «фестивальщик»лар дигән сүз дә туры килә безгә. Өченче ел 14 фестивальдә катнаштык, әлмәтлеләрдән күбрәк йөргәнбез булып чыга. Былтыр катнашулар саны буенча бер тирәдә булдык. Әмма бу гына безнең асылны тарайта. Без – новаторлар. Метафизиклар дигәндә, мин нәрсәне күздә тотам? Менә хәзер вазгыять үзгәрә, моңа коллегаларның күбесе төшенеп җитми әле. Бернәрсә үзгәрми, дип тыныч кына яшәп яту хәзерге заманга туры килми. Россия генә түгел, дөнья үзгәрә. Кытайларда «үзгәрешләр заманында туарга язмасын» дигән әйтем бар. Без шул чорда тудык. Безгә хәзер үзгәртеп кору җилләренә әзер булырга кирәк. Әле ул җил исмәгән, сызгырып кына тора. Кытайлар, теге әйтемне «үзгәрешләр җиленнән куркып, кирмән-ныгытмалар төзү – зур ялгышлык» дип дәвам итә. Чөнки ул кирмәннәр җир астында калачак. Ә бит күпме цивилизация шулай юкка чыккан! Ә инде җил искәндә кораблар төзеп, җилкәннәрне күтәрсәк, үзең булырга тиешле урынга килеп чыгарга мөмкин. Менә шуңа әзерләнергә кирәк. Безнең театр моңа әзерләнә инде.

Без чын мәгънәсендә Станиславский кузаллаган театр төзеп ятабыз. Тамашачы бездән икенче кеше булып чыгарга тиеш. Һич югы азга гына булса да үзгәрергә тиеш. Бусаганы атлап кергәндә ул әле үзен нәрсә көткәнен белми.

Адәм баласы кызык бит ул: өстәлендә бөтен нәрсә бар, күңелендә тынычлык юк. Ишегалдында 3–4 машина тезелеп тора, ул һаман канәгать түгел. Ә заман коточкыч рәвештә тиз бара. Мин аны «татар мунчасы» дим. Ковид чорында без аның салкын чоланына кердек. Быел мунчаның җылы чоланына үттек. Чөнки Россия белән Украина арасындагы низаг – әле үзгәрешләрнең башы гына. Дөньяда системалы кризис бара, Россия исә аннан гарәп әйтемендәге шикелле чыгачак. Анда болай диелгән: кәрван кискен артка борылса, алда аксак дөя булачак.

> Аксак дөя ул – Россия инде. Аңа бүтән илләргә караганда җиңелрәк булачак. Һәм Россиянең киләчәге өметле. Бер-бер артлы реформалар башланачак. Әйтик, быел мәгариф реформалары, аннары башкалары. Аннан индустриализация. Менә шулардан соң безнең ил әйдәп баручы илгә әвереләчәк.

«Татар мунчасы»на кире кайтсак, әле безнең чабынырга керәсе бар. Анысы быел башланачак. Ләүкәдә колакларны көйдереп түзеп утырасы, бөтен әшәкеләрне чыгарып чабынасы, аннары инде, иркен сулап, чәй эчәсе булачак.

Тарих кабатланучан бит ул. Без хәзер 100 ел элек булган чорны кабатлыйбыз. Гражданнар сугышы чорын әйтәм. Нәкъ шул чактагы кебек фикер каршылыгы, эмиграцияләр бара бездә дә. Заманында Ленинның киңәшчесе Бонч-Бруевич советлар дәүләте хисабына фикердәш булмаган кешеләрне – акыл ияләрен барысын да фәлсәфә поездларына яки пароходларына утыртып озатырга киңәш иткән. Бу – Бунин, Шаляпин һәм башка шәхесләр дигән сүз. Чөнки алар Россиянең киләчәген күрмәгәннәр. Бүген дә киләчәккә ышанмаган кешеләр белән алга барып булмый. «Причем» монда ышану, дисеңме? Чөнки без голограммада яшибез, анда квант законнары хөкем сөрә. Аның буенча теләсә нәрсә формага керә. Мәсәлән, синдә уй барлыкка килде һәм ул нияткә әверелде һәм син аңа ышандың, ди. Голограммада аның моделе ясала һәм тормышка аша. Әйтик, Буада театр юк иде. Миңа, халкы 18 меңнән артмаган шәһәрдә нинди театр инде, диделәр. Имеш, Яшел Үзәндә дә юк әле. Театр да булды, яңа бина да төзелеп ята. Инде эчке эшләр башланды. Чөнки Буа театр фестивалене кайдан гына килмиләр. Иран, Сербия, Эстония, Украина, Грузия, Казахстан һәм башка җирләрдән театр коллективлары килә, ә барысын да сыйдырырга мәйдан юк. Тәтеш, Апас, Кайбыч, Чүпрәле һәм Буа мәдәният сарайлары гына бар. Ә бит театр сәхнәсе ул бөтенләй бүтән: анда махсус утлар, мөмкинлекләр. Анда порталлар да бүтәнчә эшли. Менә шундый сәхнә барлыкка килеп ята бездә. Бу бина октябрьдә ачылыр дип ниятләнә, без бөтен мөмкинлекләре булган сәхнәдә эшли башлаячакбыз, Аллаһ теләсә.

:: Буа театрына татарлар гына йөриме?

– Юк, билгеле. Иң сөендергәне: тамашачы саны бермә-бер арта башлады. Дөрес, 2013–2014 елларда бик авыр булды. 2016 елда үзгәрә башладык, шул вакытта Рамил Шәрапов һәм тагын берничә артист китте. Шул елны әни дә вафат булды. Мин инде, бу театрны ябарга кирәк, дип уйлый башладым. Кәеф төшенке вакытлар иде. Аннары: «Раил, син бит метафизик», – дип үземне туктаттым. Уйда үзем теләгән театрны төзи башладым. Матур бина, тулы заллар, тамашачы театрга үзе теләп килә, аларны куып китерергә, оешмаларга кереп, билет алыгыз, дип йөрергә кирәкми. Театрга ихтыяҗ барлыкка килә. Ә ихтыяҗ булсын өчен терапия вазыйфасын үз өстенә алырга кирәк. Әйтәм бит, театрга кергән кеше, аннан үзгәреп, икенче кеше булып чыга. «Шобага» спектаклен алыйк. Тамбов, Новороссийск, Якутия, Калининград, Мичуринск, Липецк, Санкт-Петербургта рус тамашачысына уйнап кайттык. Колакчыннар киеп, рус тамашачысы карады! Татар әбиләре тарихын чагылдырган шушы спектакль буенча Грозныйда 4 сәгать фикер алыштылар. Без ул спектакль белән 5 гран-при гына алдык! Чөнки ул татар әбиләре тарихы гына түгел, аны һәр милләт үз аналарының тарихы итеп кабул итә. Менә нинди ул безнең театр!

:: Бөтен театрларның да төп функциясе шушы түгелме?

– Театр белән театр арасында аерма юк, диясең киләме? Менә хәзер карыйк инде нинди театрлар төзелде һәм кайсылары юкка чыгып бара. Сәхнәдә теләсә нәрсә эшләргә ярый, диләр. Шулай итеп Гоголь шәхесеннән һәм башкалардан карикатура иҗат иттеләр. Имеш, режиссер шулай күрә. Мөгез чыгара торгач, сәхнәгә шәрә килеш чыгу, җенси мөнәсәбәтләрне күрсәтү, алай гына түгел, хатын белән хатын, ир белән ир яратышуын күрсәтүгә кадәр барып җиттеләр. Имеш, шундый форма. Хәзер менә шулар кача инде. Сәхнә андыйны күтәрми, иртәме-соңмы чистарына ул. Менә хәзер тел чисталыгын да кайтарырга кирәк әле. Рус телен алсак та, татар телен алсак та, алынмаларга кереп баткан. Үзебез аңламаган сүзләр әле ул. Бу хакта сүз чыкса, күпләр безнең милләтнең язмышы авыр, аяныч һәм өметсез, дип әйтә. Кайсы күзлектән карасак та, шулай кебек. Татар телен күтәрергә тырышсак та, Актаныштагы балалар да, Буадагылар да – барысы да русча сөйләшә. Ата-анасы белән урысча аралашалар. Ник дисәк, ата-анасы да баласына русча җавап бирә. Татарча фикер йөртү юк.

:: Ә сез?

– Мин татарча уйлыйм. Улым да – татар.

:: Сез – татар театрымы?

– Татар театры. Әлбәттә, без русча да уйныйбыз.

:: Буа театрының сайты русча гына эшли шул.

– Шулаймыни? Әйттең, төзәтербез. «Нишләп «Дәрвиш»не русча уйнадыгыз?» – дип сораган кебек булды әле. Тиз арада чыгарырга кирәк булганга шуңа шулай килеп чыкты. Идеяне Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин биргән иде. Без, күренекле дин галиме Нургали Хәсәновка багышлап, төрле чаралар үткәрәбез. Мөфти Нургали Хәсәнов турында спектакль чыгарсагыз да яхшы була дигән иде. Әле кайчан гына мин ул кеше белән кызыксынмадым да, белмәдем дә, хәзер аны Буаны таныткан өч шәхеснең берсе дип саныйм. Алар – галим Борһан Шәһиди, рәссам Бакый Урманче һәм дин галиме Нургали Хәсәнов. Әлеге спектакль турында сүз чыкса, мин әңгәмәдәштән болай сорыйм: «Бүген өегездән чыгып китеп, Төркиягә барып, шул ил солтаны белән очрашып, аның иң дәрәҗәле кунагына әверелә алыр идегезме?» Ә ул шул дәрәҗәгә ирешкән. Өстәвенә, сараенда бер ай яшәгән, Президент хисабына Мәккәгә хаҗ кылган, солтан кулыннан иң югары дәрәҗәдәге орден алган. Нургали Хәсәнов Төркиядә китаплар чыгара, галим буларак таныла. Ә бит аяклары сызлаганга дәваланырга киткән ахун нибары. Ничек язмыш шулай үзгәрә ала? Менә шул сорауга җавап эзлибез спектакльдә. Мин анда туксанынчы елларда үзгәрә башлаган кичерешләремне дә бирергә тырыштым. Театр бит тормышымда кандидатлык минимумнарын тапшырганнан соң килеп чыкты. Аңа кадәр сәүдәдә идем. Анда «яндым», минем эш түгел ул. Ләкин анда алган тәҗрибә театрда да ярдәм итте. Әмма мин сәүдәгәр түгел.

:: Бәлки бизнесмен?

– Бизнесмен да түгел. Хәер, Уолт Диснейның шундый сүзе бар: бизнес миллион долларлар китерүгә корылган булырга тиеш түгел, миллион кешеләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә корылырга тиеш. Ул яктан караганда, мин – бизнесмен. Әмма минем хакыйкать акчага корылмаган. Кеше бәхетле булырга теләми, ул бай булырга тели, дигән бер акыл иясе. Чыннан да, кеше, баегач, бәхетле булам дип уйлый. Бичара наданлык. Андый кешенең гомере, гадәттә, дәүләтне, хатынын, һава торышын сүгеп үтә. Хәзер шундый замана: кешегә 3D форматта гына да уйлау җитми хәтта, аңа үзенең вибрацияләрен күтәрергә

кирәк булачак. Заманга иярә алмыйсың икән инде, төшеп каласың. Андыйлар да күп булачак.

:: Без үзгәртеп кору алдында, дисең. Ул кешеләрдә, шул ук театрларда ничек чагыла?

– Театрлар үзгәрә. Мин үзебезнең театрны Нух пәйгамбәрнең көймәсе итеп күз алдына китерәм.

:: Ә Камал театры?

– Анысы – Камал театры проблемасы, үзләре җавап бирерләр. Әмма Камал театрымы ул, МХАТмы – үзгәрешләр бөтен театрларда да була. Чөнки театр гына читтә кала алмый. Дөньякүләм үзгәрешләр бара икән, театр шуны чагылдырырга тиеш. Шунсыз ул алга бара алмый. Аның кирәге дә калмый. Ни өчен Нух көймәсе дип күз алдына китерәм? Тарихка күз салсак, театрның нинди генә бөек җитәкчеләре булмаган: Захаров, Любимов, Табаков... Әмма аларның һәрберсе бер чорда, ниндидер бер вакыт аралыгында гына бөек. Марсель Сәлимҗанов та – үз чорының даһи кешесе. Ә бит чор үтә, ул чикле. Фәрит Бикчәнтәевнең дә студентлары белән эшләгән вакыты – күтәрелеш вакыты. Мин аны суфи юлындагы кеше дип уйлыйм. Фикерләве шул юнәлештә. Әмма аны бөтен кеше белеп бетерми, чөнки күпләр өчен ул – «ябык» кеше. Шуңа күрә Фәритне аңлау кыенрак тоела. Әгәр ул шушы суфилыгы белән революцион эшләргә алына икән, димәк, Камал театры заман вазгыятенә җавап бирәчәк. Хәер, бу – аларның үз эше, үз юлы. Мин Буа театры өчен җавап бирәм. Менә без «Алтын битлек» орбитасына күтәрелдек. Репертуардагы 5–6 спектаклебезне бөтен җирдә күрсәтә алабыз.

:: Репертуарны тотып тора торган 5 спектакльне атап үт әле.

– «Шобага», «Бәхеткә юл кайдан?», «Тәүбә», «Фатыйма», «Дәрвиш», русча уйный торган «Барыня». Болар – бүгенге вазгыятькә корылган һәм алардан тамашачы торып чыгып китми.

:: Буа театрының йөзе булган актерлар кемнәр?

– Гөлзада Камәртдинова, Илфир Солтанов, Айгөл Сәгыйева... Алар күп һәм берсеннән берсен аерып булмас дәрәҗәгә җитеп, командага әверелеп барабыз.

:: Ә Раил Садриев?

– Ул – уйнаучы тренер: директор, режиссер, актер. Минем дошманнарым юк, чөнки берәүне дә дошман күрмим. Әмма мине дошман күрүчеләр артканнан-арта бара. Шулай диләр. Мөгаен, шулайдыр.

«Тәүбә» спектакленнән күренеш.

Бездә тикшеру өстенә тикшеру. Әле бер кеше белән сөйләшеп тордык. Ул: «Шатлан, тикшеру ул – чистарыну», – дип әйтте. Аннан соң эшләгән кешене генә тикшерәләр. Эшләмәгән кешене тикшерүдән мәгънә юк. Ә без 100 еллык тарихлы театр барлыкка китердек, аның яңа сәхифәләрен язабыз, хезмәт хаклары күләме буенча икенче урында торабыз.

:: Кадрлар мәсьәләсен ничек хәл итәсез?

– Бу – авыр мәсьәлә. Кадрлар бүлеге җитәкчесе дә, кешеләр китә, килүчеләр аз, ди. Чөнки безнең театр хәзер бүтән төрле энергиядә яши. Аны бөтен кеше дә аңлый алмый. Без өскә күтәреләбез. Мин безнең команданы театраль спецназ дип йөртәм. Жан Жак Кустоның су асты дөньясы турындагы тапшыруын күз алдына китер. Зур бер балык төркеме йөзеп бара һәм алар бер секунд эчендә кинәт кенә борылып, юлын үзгәртә ала. Ничек шулай берьюлы борылып була, кайдан сигнал килә – шаккаткыч бит. Безнең команда да шундый. Без 20 кеше – үзебез актер, үзебез монтировщик, нәрсә кирәк – шуны эшлибез. Ноябрьдә Башкортстаннан кайттык, 15 көндә 30 спектакль уйнадык. Бер көндә – икене. Һәр көнне – яңа урында. Көндез – балаларга, кич зур сәхнәдә тамашачыга уйныйбыз. Мин мактанып утырмыйм, әмма Татарстанда бер театр да безнең кебек йөрми. Әле бит бу зур акча бәрәбәренә дә түгел. Бу – чарасызлыктан. Буа – кечкенә шәһәр, анда гына утырсаң, эш бармый. Без «дальнобойщик»лар шикелле 3 көннән артык өйдә тора да алмыйбыз хәзер. Шуңа күрә мин, безнең артистлар театрдан китсә дә, эшсез калмый, дип әйтәм. Алар Россиянең теләсә кайсы мәктәбендә география укыта ала. Чөнки алар илләр, шәһәрләр күргән.

:: Бу җәһәттән бер авыр мәсьәлә бар. Театр актерсыз була алмый. Актер – театрның көче дә, йөзе дә, киләчәге дә. Шул ук вакытта ул – иң аз хезмәт хакы алучы да. Сездә хәлләр ничек?

– Хезмәт хаклары күләме буенча без – районда икенче урында. Чөнки мин актерның хәлен аңлыйм. Татарстан театр директорларыннан шул ягым белән аерылам: мин – эшли торган кәнәфиемне үзем тудырган кеше. Калганнарын кемнәрдер куйган. Ә мин башта шул кәнәфине тудырдым, хәзер шунда утырам. Тагын бер аерма: мин көн саен тамашачы каршына чыгам. Актер буларак. Чыгам да, нинди тамашачы утырганын аңлыйм. Мөгаен, мин – спектакль алдыннан чыгып, кереш сүз әйтүче бердәнбер режиссер да. Тамашачы да, актер да шулай спектакльгә җиңелрәк кереп китә. «Күпме алалар?» – дип сорыйсың килә инде. Ул сер түгел. Бездә 40 мең сумнан да ким алучы юк. 50–60 мең сум – норма. Безнең актерлар бит алар берничә эш башкара, аларга әле бу түләүләр дә әллә ни күп түгел. Эшләгән кеше алырга тиеш. Акча бит ул – энергия. Ничек инде, заводта нинди авыр хезмәттә эшләүчеләр дә бу хәтле алмый, диләр. Тиздән анда да алачаклар, дим. Үзгәрешләр чоры килә. Авыл хуҗалыгы тармагында да, башкасында да.

> Һәр нәрсәнең үз вакыты бар. Татар милләтен алыйк. Гаяз Исхакыйлар вакыты. Инде изелгән, инде бетәм дигәндә – инкыйлаб. Мәгърифәтчелек башлана. Театр үсә, гәрчә кайчан гына дин тарафыннан тыелса да. Дөрес, тальян гармун кебек, театр да безнеке булмаган. Әмма ул безнең җирлектә яңадан яралган һәм безнеке булып киткән. Татарның үсешендә катнашкан, баеткан юнәлешләр алар. Борынгы белән генә мактанып булмый, алга барырга кирәк. Аннары 1917 ел инкыйлабы, татар бүтәнчә ачыла башлый. Аннары сугыш елы, 70 нче еллар, 80 нче еллар, суверенитет, яңа формат, яңа мөмкинлекләр. Хәзер дә без яңа мөмкинлекләр алдында.

:: Ә бит җанисәп нәтиҗәләре, гомумән, сөендерерлек түгел. Анда мөмкинлекләр күренми. Татар, гомумән, кимегән.

– Татар гына түгел, Россия халкы, гомумән, күп миллионга кимегән. Кимемәскә дә була. Мәсәлән, Канадада Квебек дигән шәһәр бар, ул анда француз телендә сөйләшә торган бердәнбер кала. Англия колониясе була торып, француз телен ничек саклап калганнар соң? Хикмәт шунда: алар кимендә биш бала табу традициясен кертә. Ул әле дә бар анда. Россиягә кире кайтсак, бездә чечен милләте сан ягыннан арткан. Чөнки алар – упкын янында булган халык. Без ничек сакланып кала алабыз? Аның механизмын уйлап табасы юк. Совет заманында ул эшләгән инде. Бала табу буенча закон булырга тиеш. 1938 елдагы шикелле. Бала төшертүне тыярга. Чөнки ул хакыйкатькә каршы бару. 1938 елда Сталин шушы законны имзаламаган булса, бүген син дә, мин дә, гомумән, Россиянең ярты халкы булмаган булыр иде. 50–60 елларда тууычылар буенча бум булды. Хәзер ул юк. «Авыр заман», – диләр. Кызык инде ул халык: өендә 2–3 телевизор, икешәр бәдрәф, өстәле ризыктан сыгылып тора – аңа заман авыр. Кешелеккә зур зыян салган иң беренче нәрсә – суыткыч. Аңа кадәр халык ул кадәр ит ашамый иде. Сәламәтлеге дә нык булды. Әмма дөнья куласа. Гарәп әмире турындагы мәсәлдә мондый юллар бар: «Минем бабам далада дөядә йөргән. Мин дә дөядә йөрдем, аннары «Мерседес»ка күчеп утырдым. Минем улым да, оныгым да «Мерседес»та йөри. Ә оныкның баласына яңадан дөягә утырырга туры киләчәк. Чөнки кыен вакытлар көчле кешеләрне тудыра. Көчле кешеләр җиңел вакытларны алып килә. Ә җиңел заманда кеше көчсезләнә. Көчсез кеше авыр вакытларны тудыра». Безнең чорда әле 30 яшен тутырмаган кешеләргә комфорт зонасыннан чыгарга туры киләчәк. Аларның дөньясы җимерелә хәзер. Алар хезмәттә ватылмаган, аз укыган, калькуляторсыз куша, ала да белмиләр. Шушы буынга «Магнит»та бәрәңге үсмәгәнен, «Пятерочка»да сөт савылмаганын аңларга туры киләчәк. Бөтен нәрсәне эшләп алырга туры киләчәк. Әле авылларга кайту дулкыны көтеләчәк. Буласылар алда әле.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ВИДЕО VATANTAT.RU САЙТЫНДА

Блиц-сораштыру

– Авыл булмаса, кайда яшәр идең?

– Барыбер аерым яшәгән булыр идем. Мин барыбер үземә рәхәт булган урын төзеячәкмен.

– Соңгы укыган китабың?

– Китапларны 4–5әрне укыйм. Соңгы тапкыр 12 меңгә китап алдым. Анда Захар Прилепин да, Нургали Хәсәнов турында китап та бар, әмма күбрәк метафизика буенча китаплар җыям. Шунда Ркаил Зәйдулла шигырьләре дә, Фәнис Яруллинның көндәлеге дә бар.

– Сине сәер, диләр. Ни дәрәҗәдә?

– Мин аңламаган кешеләр өчен генә сәер. Аңлаган кешеләргә бик сәер түгел. Минем ише сәерләр заманы хәзер. Мин тылсымлы заманда яшим. Беләсеңме, ни өчен тылсымлы? Нәрсә уйлыйм – шул тормышка аша. Мин җаваплар табу халәтендә.

– Тормышыңда иң бәхетле көн?

– Бүгенге көн.

– Тормыш девизың?

– Бөтен галәм минем өчен яши һәм эшли. Минем уйларны куәтли, минем гамәлләрне мәртәбәли.

– Ачу китергеч дәрәҗәдә артыгы белән позитив син. Каян энергия аласың?

– Минем эчке халәтем белән тышкы халәтем тәңгәл. Шул тәңгәллек югалса, хәл китә, авырулар килеп чыга. Мин гармониядә яшим. 340 ел элек ата-бабаларым яшәгән төп нигездә гомер кичерәм. Телефон зарядка ала бит әле, нигез минем өчен энергия җыя торган шундый урын ул.

ЕЛЛАР һӘМ МАКСАТЛАР

2018: 5 килога ябыгырга

2019: 8 килога ябыгырга

2020: 10 килога ябыгырга

2021: 13 килога ябыгырга

2022: 15 килога ябыгырга

2023: Җәмгыять тарафыннан көчләп тагылган авырлык стандартларына каршы көрәшергә

Әз-мәз мәзәк

– Туры юл белән барасыз, иптәшләр!
– Монда юл юк бит!
– Аның каравы плакат бар.

* * *

– Безнең клиника турында бер генә начар фикер дә әйткәннәре юк.
– Шулай яхшы дәвалыйсызмы, әллә фикер әйтерлек кешеләр калмыймы?

* * *

– Егерме яшькә кадәр мин мажорик идем.
– Ә аннары?
– Ә аннары әтине утырттылар.

* * *

Ул озак йоклый алмый ятты. Башта бәрәннәр санады. Аннары кәтүче белән дуслашты. Аннары гадәттәгечә инде...

* * *

Снайпер һәвакыт «удаленка»да эшли.

* * *

Зур үскәч, иң уңайлысы шул: киемнәрең кечерәйми.

* * *

Дөньяда булмаган иң популяр уйдырма персонажлар:
– Су анасы;
– Албасты;
– репост ясап, «Айфон» откан кеше.

* * *

– Черри помидорларыгыз бигрәк ачы булган быел.
– Редис ул.

«БЕЗГӘ КИЛЕП КҮРЕГЕЗ!»

ВТ

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ КАРШЫНДАГЫ
ТАТАР ТЕЛЕН һӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЯШӘҮЧЕ
ХАЛЫКЛАР ВӘКИЛЛӘРЕНЕҢ ТУГАН ТЕЛЛӘРЕН САКЛАУ,
ҮСТЕРҮ КОМИССИЯСЕ

И туган тел, и матур тел...

Һәр җирлекнең – үз асылы. Сөйләме дә үзгә, үз гадәтләре, бәйрәмнәре бар. Кешеләр һәм аларның яшәеше дә, кайда гомер кичерүләренә карап, бер-берсеннән аерыла. Ә сезнең авыл/шәһәр/район үзеге кешеләре бүген нәрсә белән яши? Сезгә килсәк, горурланып, нилар күрсәтәчәксез? Ә иң мөһиме – сезнең җирлектә яшәүчеләр көндәлек тормышта татар телен ничек саклый? Авыл/шәһәрегезнең яшәеше һәм татар теленең көндәлек тормышта кулланылышын тасвирлаган видеозмалар көтеп калабыз.

Гран-при 50 000 сум

ҖИҢҮЧЕЛӘРГӘ 25 000 сум ▶ Кызыксындыру бүләге 15 000 сум

- **ВИДЕО ТӨШЕР** (хронометражы – 5 минутка кадәр, формат – горизонталь)
- **ҖИБӘР:** konkurs_vt@mail.ru
- **ТАВЫШ БИРҮДӘ КАТНАШ:** vatantat.ru vatanimtatarstan

Видеоматериаллар 10 майга кадәр кабул ителә
Сораулар булса: 8 (843) 222-09-64

Бәйгенең нигезләмәсе һәм шартлары

НОМИНАЦИЯЛӘР

▶**10–17 ЯШЬЛЕКЛӘР** (1 җиңүче, 2 кызыксындыру бүләге)
▶**18–34 ЯШЬЛЕКЛӘР** (1 җиңүче, 2 кызыксындыру бүләге)
▶**35 ЯШЬ һӘМ ӨЛКӘНРӘКЛӘР** (1 җиңүче, 2 кызыксындыру бүләге)
▶**ГРАН-ПРИ** (1 җиңүче)

Конкурста бер эш белән бер автор яки авторлык коллективы катнаша ала. Бәйге 2023 елның 23 гыйнварыннан алып 2023 елның 10 июненә кадәр үткәрелә.

6+

Беләсең килсә...

1 Дубайда урнашкан Бурдж-Халифа бинасында ничә лифт бар?
а) 46;
б) 57;
в) 63.

2 Федераль Җыенның югары палатасы ул –
а) Дәүләт Думасы;
б) Дәүләт Советы;
в) Федерация Советы.

3 Татарлар шактый яшәгән бу шәһәргә 1663 елда нигез салынган дип исәпләнә:
а) Пенза;
б) Ырынбур;
в) Пермь.

4 Америкада яшәүче җырчы Иделия – кемнең кызы?
а) Марс Шабаев;
б) Марс Макаров;
в) Марс Тукаев.

Җаваплар:
1. б); 2. в); 3. а); 4. б).

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15536 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 208

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+